ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ
ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

# ЭШ ПРОГРАММАЛАРЫН ТӨЗҮ БУЕНЧА МЕТОДИК ТӘКЪДИМНӘР

## (5 НЧЕ СЫЙНЫФ ӨЧЕН “ТАТАР ТЕЛЕ” ПРЕДМЕТЫ БУЕНЧА ЭШ ПРОГРАММАСЫ)

Казан
2015

**ББК 74.268.1Тат**
**Э98**

**Проект җитәкчесе:**
**Хәмитов Р. Г.,** Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты ректоры, педагогика фәннәре кандидаты, доцент

**Төзүче-авторлар:**
**Шәмсетдинова Р. Р.,** Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, филология фәннәре кандидаты, доцент (Проект группасы **җитәкчесе)**

**Хадиева Г. К.,** филология фәннәре кандидаты, татар теле һәм укыту методикасы кафедрасы доценты (КФУ ИМФИ)

**Фатхуллова К. С.,** педагогика фәннәре кандидаты, гомуми лингвистика, лингвокультурология һәм тәрҗемә белеме кафедрасы доценты (КФУ ИМФИ)

**Денмухаметова Э. Н.,** филология фәннәре кандидаты, гомуми лингвистика, лингвокультурология һәм тәрҗемә белеме кафедрасы доценты (КФУ ИМФИ)

**Муллахмәтова Р. К.,** Казан шәһәре Киров районы 137 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Валиева М. Н.**, Казан шәһәре Идел буе районы 24 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Гыйниятуллина А. Р.**, Казан шәһәре Идел буе районы 16 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Сафиуллина Ф. С.,** Казан шәһәре Идел буе районы 16 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Сиражетдинова З. П**., Казан шәһәре Авиатөзелеш районы 49 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Дәүләтшина Л. А.,** Казан шәһәре Авиатөзелеш районы 49 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

“Татар теле” предметының эш программасын төзү буенча методик тәкъдимнәр “Россия Федерациясендә Мәгариф турында”гы Федераль законы (№ 273-ФЗ, 29.12.2012), федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә һәм гомуми белем бирүнең төп белем бирү үрнәк программаларын исәпкә алып эшләнде.

Методик тәкъдимнәрдә бирелгән материал белем бирү оешмалары җитәкчеләре, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, методистлар өчен файдалы булачак.

© ТРМҮИ, 2015

# КЕРЕШ

Федераль дәүләт белем бирү стандартларын гамәлгә кую Россия Федерациясенең гомуми белем бирү системасында зур үзгәрешләр тудырды. Әлеге документ барлык төр белем бирү оешмалары өчен мәҗбүри саналган кагыйдә һәм таләпләрне үз эченә алган һәм укыту программаларының нигезен тәшкил иткән төп норматив-хокукый акт булып тора.

Белем бирү процессын Федераль дәүләт белем стандартлары таләпләре буенча оештырганда «төп гомуми белем бирүнең эчтәлеген укучы нәрсә белергә (истә калдырырга, кабатларга) тиеш дигән сорауга җавап кына түгел, уку эшчәнлеген мөстәкыйль оештыруны тәэмин итә торган шәхескә кагылышлы, коммуникатив, танып белү, регулятив универсаль уку гамәлләрен формалаштыруны да» исәпкә алырга кирәк. Шуңа бәйле рәвештә бөтен уку-укыту процессы универсаль уку гамәлләрен формалаштыру һәм бәяләүгә корыла. Татар телен укытуга килгәндә, телгә кагылышлы теоретик материалны яхшы үзләштергән, үз туган телендә камил итеп сөйләшә, үз фикерен дөрес итеп формаштыра, башка телләр белән кызыксынучы, аларны ихтирам итүче, ТР ике дәүләт телендә аралаша ала торган билингваль һәм полилингваль шәхес тәрбияләү максаты куела.

Мәгълүм булганча, һәр уку предметының эчтәлеге укытучы тарафыннан төзелгән эш программасында чагылыш таба.

Укыту предметы буенча төзелгән эш программасы укытучының белем бирү эшчәнлеген оештыру системасын характерлый торган норматив-идарә итү документы(аңлатма язуы, уку предметының эчтәлеге, программаның бүлек һәм темаларны үз эченә алган календарь-тематик план, белем бирүнең планлаштырылган нәтиҗәләре, әлеге нәтиҗәләргә ирешүне бәяләү юллары һәм формалары) булып тора. Ул укытучы тарафыннан үрнәк эш программасына нигезләнеп төзелә. Программаларны эшләү гомуми белем бирү оешмаларының уку-укыту, методик һәм норматив эшчәнлекнең аерылгысыз бер өлеше булып санала. Шул ук вакытта “Россия Федерациясендә Мәгариф турында”гы 273 нче номерлы Федераль законы уку предметы, курсы, дисциплинасының (модуленең) эш программасы дигән төшенчәне үз эченә алса да, биредә әлеге төр программага куела торган таләпләр билгеләнми, шул сәбәпле укытучы эш программасын төзегән вакытта төрле сораулар белән очрашырга мөмкин.

Әлеге методик тәкъдимнәрдә татар теле предметы буенча эш программасының моделен төзү буенча киңәшләр бирелә, эш программасының структурасы, төп өлешләре, аны төзү юнәлешләре билгеләнә.

Эш программасының структурасын, өлешләрен төзүдә аерым уку предметының үрнәк программасының билгеле параметрлары хезмәт итә, чөнки үрнәк программа, югарыда билгеләп кителгәнчә, эш программасы төзү нигезләренең берсен тәшкил итә.

Эш программасын төзегәндә аның максатларын, бурычларын һәм функциясен билгеләү мөһим.

Эш программасының төп максаты – белем бирүнең билгеле бер баскычында төп белем бирү программасының, уку планында каралган сәгатьләр санына туры килгән аерым ук предметы буенча үрнәк программаның эчтәлеген, дәрестән тыш эшләр планын, өстәмә белем бирү сәгатьләрен тормышка ашыру.

Эш программасының бурычларын түбәндәгеләр тәшкил итә:

- гомуми белем бирү оешмасының белем бирү эшчәнлегенең максатлары, бурычлары һәм укучыларның үзенчәлекләрен исәпкә алып аерым уку предметының эчтәлеген, күләмен, уку материалын өйрәнү тәртибен билгеләү;

- уку еллары һәм белем алу баскычлары эчтәлегенең дәвамчанлыгын тәэмин итү;
- төп гомуми белем бирү оешмасының билгеле бер шартларын, уку ихтыяҗларын һәм укучыларның үсеш үзенчәлекләрен исәпкә алып, педагогик эшчәнлекнең индивидуальлеген чагылдыру.

Эш программасының төп функцияләре:

- норматив (эш программасы тулы күләмдә эшләнергә тиеш);
- билгеле бер нәтиҗәгә исәп тоту (уку-укыту процессына кертүнең максатларын билгели);
- эчтәлекле (укучыларның үзләштерергә яки танышырга тиеш булган аерым уку предметы эчтәлеге элементларының составын билгели);
- аерым уку предметы буенча белем бирүнең эчтәлегендә дәвамчанлыкны булдыра;
- белем бирү эчтәлегендә интегратив юнәлеш принцибын тормышка ашыра;
- региональ предмет эчтәлегенең модульләрен үз эченә ала;
- системалы-эшчәнлекле юнәлешне тормышка ашыру өчен шартларны тәэмин итә;
- һәр укучының планлаштырылган нәтиҗәләренә ирешүен тәэмин итә;
- процессуаль (эчтәлек элементларын үзләштерүнең логик эзлеклелеген, уку-укытуны оештыру формаларын, методларын, чараларын һәм шартларын билгели);
- бәяләү (ФДББСны тормышка ашыру шартларында белем бирүнең дәрәҗәсенә туры килгән гомуми белем бирү программаларын үзләштерүдә предмет һәм метапредмет нәтиҗәләргә ирешү дәрәҗәсен ачыклый; ФДББСны тормышка ашыру шартларында эчтәлекне үзләштерү дәрәҗәләрен, контроль объектларын һәм укучыларның белем дәрәҗәсен бәяләү критерийларын билгели).

Аерым уку предметы буенча эш программасы түбәндәге өлешләрдән гыйбарәт:

1) аңлатма язуы (биредә аерым уку предметы спецификасын исәпкә алып, төп гомуми белем бирүнең гомуми максатлары конкретлаштырыла);
2) аерым уку предметының гомуми характеристикасы;
3) уку предметының гомуми уку планында тоткан урыны;
4) аерым уку предметын үзләштерүнең шәхескә кагылышлы, метапредмет һәм предмет нәтиҗәләре;
5) аерым уку предметының эчтәлеге;
6) укучыларның төп уку эшчәнлеге төрләрен билгеләгән тематик планлаштыру;
7) уку-укыту процессының укыту-методик тәэмин ителеше тасвирламасы;
8) аерым уку предметын өйрәнүнең планлаштырылган нәтиҗәләре.[1]

Аерым уку предметы буенча эш программасын килештерү һәм раслауның тәртибе гомуми белем бирү оешмасының локаль норматив актлары белән билгеләнә.

[1] “Төп гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартларын раслау турында”гы Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының боерыгы (№1897, 17.12.2010)

## РУС ТЕЛЕНДӘ УРТА (ТУЛЫ) ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘПЛӘРЕНЕҢ ТАТАР ТӨРКЕМЕНДӘГЕ 5 НЧЕ СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫ ӨЧЕН ТАТАР ТЕЛЕ БУЕНЧА БЕЛЕМ БИРҮ ПРОГРАММАСЫ

**Дәреслек: Шәмсетдинова Р.Р., Һадиева Г.К., Һадиева Г.В.** Татар теле. Рус телендә урта (тулы) гомуми белем мәктәбенең 5 нче сыйныфында укучы татар балалары өчен дәреслек. Казан – “Мәгариф – Вакыт” нәшр.. 2015.

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

5 нче сыйныфлар өчен татар теленнән эш программасы Россия Федерациясендәге һәм Татарстан Республикасындагы мәгарифкә кагылышлы хокукый-норматив актларга һәм федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп төзелде:

1. Россия Федерациясенең “Мәгариф турында”гы Законы (Федеральный закон от 29.12.2012 273-ФЗ “Об образовании в Российской Федерации”).
2. Татарстан Республикасының “Мәгариф турында”гы Законы (Закон Республики Татарстан “Об образовании” № 68-ЗРТ от 22 июля 2013 года, статья 8).
3. Россия Федерациясенең “Россия Федерациясе халыктелләре турында”гы 126-ФЗ нчы номерлы Законы (24.07.1998).
4. РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы приказы, 30 нчы август, 2013 нче ел №115 (“Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам – начального общего, основного общего и среднего общего образования”).
5. “Татарстан Республикасының халык телләре турында” Законы (Закон Республики Татарстан от 08.07.1992 № 1560-XII (ред. от 03.03.2012г.) “О государственных языках Республики Татарстан и других языках в Республике Татарстан”).
6. “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы, 2004нче ел, 1нче июль.
7. “2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы”, 2013 нче ел, 25 нче октябрь, 794 нче карар.
8. Төп гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандарты (Россия Мәгариф һәм Фән министрлыгында 2010 нчы елның 17 нче декабрь боерыгы 1897 нче номер белән расланган, РФ Юстиция Министрлыгында 19644 нче регистрацион номеры белән 2011нче елның 1 нче февралендә теркәлгән).
9. Татарстан Республикасында 2012-2020 нче елларда фән һәм мәгариф үсеше турында “Дәүләт программасы”.
10. 2010-2015 нче елларда Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү стратегиясе “Киләчәк” программасы.

5 нче сыйныф өчен "Татар теле " курсының эш программасы Федераль дәүләт белем бирү стандартларының таләпләренә туры китереп, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән “Рус телендә Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен укыту программасы (татар балалары өчен)”, (төзүче-авторлары: Ф.Ф. Харисов, Ч.М. Харисова. В.А. Гарипова – Казан, 2011.), Рус мәктәбендә укучы татар

балаларына татар теленнән үрнәк гомуми программа. V - IX сыйныфлар, (төзүче-авторлары: Ф.Ф. Харисов, Ч.М. Харисова. Г.Р. Шакирова - Казан, 2013.) 5 нче сыйныф өчен Р.Р. Шәмсетдинова, Г.К.Һадиева, Г.В. Һадиева тарафыннан төзелгән (Казан: "Мәгариф – Вакыт" – 2015.) Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслеккә нигезләнеп төзелде.

Дәреслек: Рус телендә урта (тулы) гомуми белем мәктәбенең 5 нче сыйныфында укучы татар балалары өчен дәреслек. – Казан :"Мәгариф – Вакыт" нәшр. 2015.

**Рус телендә белем бирү мәктәбендә татар балаларына татар теле укытуның максаты:**

Укучыларда ана телен өйрәнүгә кызыксыну, аның аркылы башка телләрне дә өйрәнү теләге уяту; үз милләтеңә, аның мәдәни үзенчәлекләренә, гореф-гадәтләренә, ана телеңә мәхәббәт тәрбияләү; шулар аркылы башка милләтләргә, аларның гореф-гадәтләренә, мәдәниятләренә ихтирам уяту.

Балаларда туган телгә, аның яңгырашына, сүзлек байлыгына карата кызыксыну уяту. Тел күренешләрен аңларга, эзлекле фикер йөртергә өйрәтү. Фәнни-тикшерү эшчәнлеге алып баруга мотивация тудыру, проект эшләрен башкаруны дөрес оештыру. Тел берәмлекләрен урынлы кулланып, бәйләнешле сөйләм тудыру өстендә эшләү, аралашу компетенциясе булдыру.

**Бурычлары:**

- укучыларда, туган телгә сакчыл караш тәрбияләү;
- укучыларның сөйләм эшчәнлеген һәм фикерләү сәләтен, төрле шартларда әдәби телдә дөрес аралаша белү күнекмәләрен үстерү;
- татар теленең фонетик төзелеше, орфоэпик, орфографик нормалары турында белем бирү;
- телнең лексик байлыгын анализлый, күрә, таба белү сәләтен, осталыгын булдыру, үстерү, сүз байлыгын арттыру;
- татар теленең сүз ясалыш мөмкинлекләрен үзләштерү, гамәли кулланылышка кертү;
- алынган белемне һәм осталыкны тормышта максатчан кулланырга өйрәтү;
- сүзлекләр, дәреслек, өстәмә һәм белешмә әдәбият белән эш итү, уку, язу күнекмәләрен камилләштерү;
- үз милләтеңә, телеңә хөрмәт белән карау, шулай ук татар теле аша башка милләт вәкилләренә, аларның рухи мирасына мәхәббәт хисе тәрбияләү.

**Белем дәрәҗәсенә таләпләр:**

- фонетик, сүз ясалышы һәм лексик закончалыкларны күрә белү;
- сүзне катлаулы тел берәмлеге буларак бәяләүгә ирешү;
- төрле тип сүзлекләрнең төзелү принципларын үзләштерү;
- татар теленең сүз ясалыш ысулларын таный һәм аера белү;
- укылган текстның эчтәлеген аңлау;
- укылган текстка үз мөнәсәбәтләрен белдерү;
- укылган текстка бәйле рәвештә телдән һәм язмача фикер белдерү;
- сыйныфташлары һәм укытучы белән фикер алышу, үз фикерен дәлилли белү;
- тәкъдим ителгән темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү.

**Күнекмәләргә таләпләр:**

**Фонетика, орфоэпия, лексика, съз ясалышына караган белемнәрен тирәнәйтү:**

- авазларны классификацияли белү күнекмәләрен тирәнәйтү;

- сүзләрне иҗекләргә бүлә белү, басым кую үзенчәлекләрен үзләштерү;
- җөмләләрнең мәгънәви-интонацион үзенчәлекләрен үзләштерү юнәлешендә күнекмәләр өстендә эшләү.
- сүзләргә фонетик анализ ясый белү;
- сүзлек составын килеп чыгышы ягыннан бәяли белү;
- сүзлек составын куллану өлкәсе һәм активлыгы буенча куллана белү;
- сүзлекләр белән эшли белү;
- татарчадан русчага һәм русчадан татарчага тәрҗемә итү күнекмәләре булдыру;
- яңа сүзләр ясау күнекмәләрен үзләштерү.

**Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләре булдыру:**

- җөмләләр төзергә өйрәтү, бәйләнешле сөйләм үстерү өстендә, сөйләм күнекмәләрен барлыкка китерү юнәлешендә эшләү;
- план нигезендә кечкенә хикәя төзи белү;
- репликага нигезләнеп, логик бәйләнешле диалог төзи белү;
- дөрес уку һәм язу күнекмәләре булдыру, тасвирлама, хикәяләү, фикер йөртүне активлаштыруга этәргеч булырлык текстлар төзү күнекмәләрен ныгыту;
- сочинение, изложение язарга өйрәнү;
- укучыларда татар мәдәниятенә караган мәгълүматларны үстерүгә ирешү;
- картина буенча сочинение язу күнекмәләре булдыру;
- проектлар төзү күнекмәләрен ныгыту.

**Уку фәненең уку планында тоткан урыны**

Укыту-тәрбия эше рус телендә алып барыла торган мәктәпләрдә татар балаларына татар телен өйрәтү үз телләрен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш уяту, мәхәббәт хисләре тәрбияләүдә әһәмиятле роль уйный.

Укыту планында каралганча, татар теле дәресләре өчен эш программасы атнага 3 сәгать исәбеннән елга 105 сәгатькә төзелде.

**Укытуның көтелгән нәтиҗәләре**

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:**

- шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү:
- милли горурлык, гражданлык хисләре формалаштыру;
- әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү;
- күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үз алдыңа максат кую, аңа ирешү юлларын эзләү;
- уңышларыңа яки уңышсызлыкларыңа, аларның сәбәпләренә дөрес бәя бирү;
- - индивидуаль эшчәнлек стилен формалаштыру:
- төрле мәгълүмат чараларын (сүзлекләр, Интернет ресурслар һ.б.) танып-белү һәм аралашу вакытында куллану;
- актив, мөстәкыйль, иҗади фикер йөртүче, фәнни-тикшеренү эшчәнлеген башкара алырлык шәхес буларак формалашуны дәвам итү;
- үзең алган белем күнекмәләрен тормышның төрле шартларында куллана белергә өйрәнү.

**Метапредмет нәтиҗәләр**

**Танып-белү гамәлләре:**

- танып-белү юнәлешендәге максатларны билгеләү;
- укучының үз эшчәнлеген мөстәкыйль рәвештә оештыра
- белүе, бәяләве, үзенең кызыксынучанлык өлкәсен билгеләве;

- мөстәкыйль рәвештә теманы, куелган проблеманы ача белү, фикер йөртү;
- уку мәсьәләсе тирәсендә логик фикерләү;
- фикерләүдә логик чылбыр төзү;
- тема тирәсендәге төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;
- төрле мәгълүмат чаралары белән эшли, кирәкле мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлегендә куллана белү;
- фонетик анализ ясау күнекмәләре булдыру;
- сүз ясалыш ысулларыннан файдаланып сүзләр ясый белү , сөйләм эшчәнлегендә алардан дөрес һәм урынлы файдалана белү;
- телне әдәбият, рәсем һәм музыка сәнгате белән бәйләп, сүз сәнгатенең кыйммәтен күрсәтү, матурлыкны танырга өйрәтү;
- тел берәмлекләренең әдәби әсәр тудырудагы ролен билгеләү;
- татарчадан русчага, русчадан татарчага тәрҗемә итү юлы аша фразеологик берәмлекләрнең эчтәлегендәге фәлсәфәне үзләштерү.

**Коммуникатив УУГ**

- тыңлый белү;
- диалог төзүдә һәм коллектив фикер алышуда катнашу;
- сыйныфташлары һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү;
- төрле фикерләрне исәпкә алып эш итү;
- үз фикерен дәлилли белү, тормыштан мисаллар китерү;
- төрле җавапларны тыңлау, чагыштыру, нәтиҗә ясау;
- үз фикерен тулы һәм төгәл итеп әйтә белү;
- күмәк эш вакытында уртак фикергә килү;
- мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек итүдә инициативасы күрсәтү;
- укылган текстлар буенча сораулар бирә алу;
- бирелгән текстларның дәвамын үзлектән сөйләп карау,фикер әйтү автор фикере белән чагыштыру;
- үз эшен контрольдә тоту, сыйныфташларына ярдәм итү;
- коммуникатив күнекмәләрнең кеше тормышындагы ролен билгеләү;
- үз фикерләрен телдән һәм язмача җиткерә белү;
- башкаларны тыңлый, киңәш бирә белү;
- сыйныфташлары каршында төрле темаларга, башкарылган проектлар буенча чыгыш ясау;
- иптәшенең гамәлләрен бәяләү, күрше белән хезмәттәшлек итү.

**Регулятив УУГ:**

- дәреснең проблемасын (тема) һәм максатларын мөстәкыйль формалаштыру;
- проблеманы аңлап гипотеза чыгару, үз фикереңне дәлилләр китереп раслый белү, телдән (диалогик, монологик) һәм язма сөйләмдә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен аерып алу, нәтиҗәләрне формалаштыру;
- максатка ирешү юлларын билгеләү;
- үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәле булуына ирешү, үз эшчәнлегеңне контрольгә алу;
- укытучы белән бергәләп, үз эшен, иптәшләренең җавапларын бәяләү;
- кагыйдә, күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу;
- эшләнгән эшкә бәя бирү, сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.

**Предмет нәтиҗәләр:**

- фонетик, сүз төзелеше һәм лексик берәмлекләр белән эш итүне ныгыту;
- исем, орфоэпик һәм орфографик кагыйдәрне үзләштерү, гамәли куллана белү;
- сүзнең лексик мәгънәсен билгели һәм сөйләмдә урынлы куллана белү;
- тел материалы белән логик фикерләүне сорый торган эш төрләрен башкару;
- телнең сүзлек составын куллану өлкәсе, активлыгыннан чыгып урынлы файдалану;
- сүзләрнең төзелешен һәм ясалышын тикшерү;
- бирелгән темаларга, тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп, кечкенә хикәяләр язу;
- укучыларны иҗади эшчәнлеккә тарту, проект эшләре белән кызыксындыру.

**Курсның эчтәлеге**

**4 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау**

Лексикология буенча үткәннәрне кабатлау.

Башлангыч сыйныфларда исем, сыйфат, сан, алмашлык, фигыль буенча үткәннәрне кабатлау.

Синтаксис буенча өйрәнгәннәрне кабатлау: сүзтезмә һәм җөмлә; җөмләнең баш кисәкләре; җәенке һәм җыйнак җөмләләр; җөмләнең иярчен кисәкләреннән аергыч; җөмләнең тиңдәш кисәкләре.

**Фонетика, орфоэпия, графика, орфография**

Фонетика һәм орфоэпия турында гомуми төшенчә.

Сөйләм органнары. Авазларның ясалышы. Сөйләм аппараты.

Татар телендә сузык һәм тартык авазлар.

Татар телендә сузык авазларның әйтелеше. Сингармонизм законы: рәт һәм ирен гармониясе.

Тартык авазлар классификациясе. *[къ], [к]* һәм *[гъ], [г]* тартык авазлары. *[һ]* һәм *[х]* тартык авазлары. *[w]* һәм *[в]* тартык авазлары. *[н]* һәм *[ң]* тартык авазлары. *[ʼ]* (һәмзә) тартыгы.

Тартык авазларның сөйләмдәге үзгәреше. Тартыклар чиратлашуы. Борын ассимиляциясе. Ирен ассимиляциясе.

Татар телендә иҗек. Сүзләрне юлдан-юлга күчерү. Сүз басымы. Интонация.

Графика һәм орфография. Аваз һәм хәреф төшенчәләре. Татар алфавиты.

Сузык аваз хәрефләре. *О, ө, е, э* хәрефләренең дөрес язылышы. Икешәр аваз кушылмасын белдергән *е, ю, я,* хәрефләренең дөрес язылышы.

Тартык аваз хәрефләре. *ъ* һәм *ь* хәрефләренең дөрес язылышы. *В, к, г* хәрефләре.

Сүзләрне кушып, сызыкча аша һәм аерып язу. Баш һәм юл хәрефләре.

Сүзләргә фонетик анализ ясау.

Кабатлау.

**Лексикология**

Лексикология. Лексика һәм лексикология турында төшенчә. Сүзнең лексик мәгънәсе, аны аңлату юлларын аңлату. Аңлатмалы сүзлекләр. Сүзләрне мәгънәләре, килеп чыгышыннан һәм кулланылышы ягыннан төркемләү.

Бер һәм күп мәгънәле сүзләр.

Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре.

Синоним. Антоним. Омоним.

Килеп чыгышы ягыннан татар теленең сүзлек составы. Гомумтөрки һәм алынма сүзләр. Татар сүзләренең төркемнәре.

Куллану өлкәсе буенча татар теленең сүзлек составы. Гомуми кулланылыштагы (гомумхалык) һәм кулланылышы чикләнгән (диалекталь һәм һөнәрчелек сүзләре) сүзләр.

Куллану активлыгы буенча сүзлек составы: искергән һәм тарихи сүзләр. Искергән сүзләр турында төшенчә.

Яңа сүзләр (неологизмнар).

Фразеологизмнар. Фразеологик әйтелмәләрне сөйләмдә куллану.

Сүзгә лексик анализ ясау.

Кабатлау.

**Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы**

Сүзнең тамыры һәм кушымчалар. Сүзнең мәгънәле кисәкләргә бүленеше.

Мөнәсәбәт белдерә торган кушымчалар: модальлек һәм бәйләгеч кушымчалар.

Модальлек кушымчалары. Исем, сан, сыйфат, фигыльләргә ялгана торган модальлек кушымчалары.

Сүзнең нигезе. Тамыр һәм ясалма нигезле сүзләр.

Сүзләрне төзелеше буенча тикшерү.

Сүз ясалу ысуллары. Ясагыч кушымча ялгау ысулы. Сүзгә кушымчалар ялгану тәртибе.

Сүзләрне кушу ысулы: кушма, парлы һәм тезмә сүзләр ясалу.

Сүзләрне кыскарту ысулы.

Кабатлау.

**5 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау**

**Бәйләнешле сөйләм үстерү**

Төрле характердагы диктантлар язу.

Хаталар өстендә эш башкарган вакытта телдән һәм язма рәвештә анализ ясау.

Мәкаләне редакцияләү.

Әдәби текстларның эчтәлеген сөйләү.

Изложение һәм сочинение язарга өйрәнү.

Бирелгән темага, рәсемгә яки планга нигезләнеп, хикәя төзеп язу.

Бирелгән текстка план төзү.

Текстларны, мәкальләрне, фразеологик әйтелмәләрне бер телдән икенче телгә тәрҗемә итү. Сүзлекләрдән файдалану.

Проектлар төзү.

Картина буенча сочинение язу (Х.Якупов «Канәфер чәчәге. Натюрморт», И. Шишкин «Имәнлек»)

**Тематик планлаштыру**

| № | Төп темалар | Уку-укыту эшчәнлеге | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|---|
| 1. | Башлангыч сыйныфта үткәннәрне кабатлау | Сүз төркемнәре, җөмлә турында үткәннәрне системага салып кабатлату | 5 |
| 2. | Фонетика, орфоэпия. Графика һәм орфография. | Графика һәм орфография. Аваз һәм хәреф төшенчәләрен аеру. Татар алфавитын үзләштерүне гамәли ныгыту. Татар теленең үзенчәлекле авазларын дөрес әйтү, язу. Аваз үзгәрешләрен таба һәм билгели белү. Сүзләрне юлдан-юлга күчерү, иҗек калыпларына нигезләнеп, сүзләрне иҗекләргә бүлү. | 33 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Сүз басымын дөрес кую. Текстка ярашлы интонация төрен билгеләү һәм куллану | |
| 3. | Лексикология һәм лексикография. | Текстта, сөйләмдә сүзнең кулланылыш үзенчәлеген, лексик мәгънәсен билгеләү. Сүзләрнең актив, пассив кулланылышларын аңлату. Сүзләрнең килеп чыгышларын билгеләү, сәбәпләрен аңлау. Фразеологик берәмлекләр белдергән мәгънәне аңлату, сөйләмдә алардан урынлы куллану. Сүзлекләр белән белешмә материал буларак эшләү | 14 |
| 4. | Сүз төзелеше һәм ясалышы. | Сүзләрне тамырга һәм кушымчага таркату.Төрле сүз төркемнәрен ясаучы кушымчаларны билгеләү. Мөнәсәбәт белдерүче, бәйләгеч кушымчалар, модальлек кушымчаларын аеру, урынлы куллану. Сүз ясалу ысулларын үзләштерү, тексттан табу дөрес билгеләү | 23 |
| 5. | Кабатлаулар | 5 нче сыйныфта үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау | 6 |
| 6. | Бәйләнешле сөйләм үстерү | Бирелгән терәк сүзләрне кулланып, бирелгән планга таянып, кечкенә хикәя төзү. Хикәя һәм сорау җөмләләрне файдаланып, диалогик сөйләм төзү. Изложение һәм сочинение язарга өйрәнү. Төрле характердагы диктантлар язу | 24 |

**Укытуның материаль-техник һәм мәгълүмати тәэмин ителеше**

- белем һәм тәрбия бирү өчен барлык шартлар да тудырылган, санитария һәм янгыннан саклану нормаларына туры килгән уку бинасы булу;
- әдәбиятны өйрәнү өчен җитәрлек күләмдә дәреслекләр һәм өстәмә методик ярдәмлекләр белән тәэмин ителгән китапханә;
- электрон китапханә, башка электрон ресурслар, татарча сайтлардан куллану мөмкинлеге булган компьютер классы;
- лингафон кабинеты;
- электрон һәм басма күрсәтмә әсбаплар, дәреслекләр;
- мультимедиа укыту программалары, компьютер программалары;
- укучыларының белемнәрен тикшерү программалары;
- төрле типтагы сүзлекләр, энциклопедияләр;
- белешмә материаллар;
- балалар өчен чыгарылган газета һәм журналлар;
- интерактив тикшерү программалары;
- татар сайтлары (belem.ru; tatarile.org.com).

**Әдәбият исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән “Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы (татар балалары өчен): 1-11 нче сыйныфлар. – Казан: Мәгариф, 2010.

2. Укыту фәннәре буенча эш программалары: татар теле: методик тәкъдимнәр. Төп гомуми белем мәктәбе. – Казан: ДБО “Белем сыйфаты мониторингының республика үзәге, 2013. – 116 б.

3. Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 239 б.

4. Сафиуллина Ф. С. Хәзерге татар әдәби теле. Югары һәм урта уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: “Мәгариф” нәшр., 2006.

5. Хәбибуллина З.Н., Нәбиуллина Г.Ш. Диктантлар җыентыгы: Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5 – 11 сыйныфлары өчен:Укытучылар өчен кулланма. – Казан: “Мәгариф” нәшр., 2006.

6. Шәмсетдинова Р.Р. Татар теле: Күнегүләр. Анализ үрнәкләре. Тестлар. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2005. – 160 б.

7. Татар теле: Рус мәктәбендә төп гомуми белем бирү оешмаларында (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән) эшләүче укытучылар өчен методик әсбап. 5 нче сыйныф./ Р.Р.Шәмсетдинова, Г.К.Һадиева, Г.В. Һадиева. – Казан: “Мәгариф – Вакыт” нәшр., 2015.

**Өстәмә әдәбият**

1. Фатыйхова Р.Н. Татар теленнән диктантлар, контроль эшләр, тестлар. – Казан, “Гыйлем” нәшрияты, 2009.
2. Максимов Н.В. “Урта мәктәптә татар теле укыту: Фонетика. Морфология.”Укытучылар өчен методик кулланма. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2004.
3. “Фән һәм мәктәп”, “Мәгариф” журналлары, “Мәгърифәт”, “Ачык дәрес” газеталары.

**Мәгълүмат чыганаклары**

http://www.ed.gov.ru
Белем бирү буенча федераль агентлык
http://www.apkppro.ru РФ мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү
һәм профессиональ әзерләү академиясе
http://www.lexed.ru Федеральный центр образовательного законодательства
http://www.rustest.ru Федераль тест үткәрү үзәге
http://www. tatedu.ru ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы
http://www.edu. kzn.ru ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы Белем порталы
http://www.mon.tatar.ru
http://www.shoolexpo.ru
http://. belem.ru
http://. tatar.ru ТР рәсми серверы
http://. Tat. Tatar-inform.ru ТР мәгълүмат агентлыгы
http://. intertat.ru ТР электрон газетасы
http://. xat.ru Татар хат алышу хезмәте
http://. suzlek.ru on-line русча сүзлек
http://. Kitapxane.at.ru татар телендәге әдәби әсәрләр китапханәсе
http://. Tatar.com.ru татар теле сүзлекләр һәм үзөйрәткечләр
http://. Tatarca.boom.ru татарча текстлар
http://. tataroved.ru Татар тарихы: төрки-татар дөньясы
http://. selet.ru “Сәләт” яшьләр
http://. Kitapxane.at.ru татар телендәге әдәби әсәрләр китапханәсе
http://. Tatarca.boom.ru татарча текстлар

Электрон ресурслар: “Бала” китапханәсе, “Татар мультфильмнары”, мультимедиа укыту программалары; электрон китапханә; татар сайтлары (belem.ru, tatarile.org.com);

**Кушымта**

## Календьдар-тематик план[1]

Барлыгы – 105 сәгать (* билгесе белән бәйләнешле сөйләм үстерү курсәтелде)

| № | Дәрес темасы | Дәрес саны | Төп эчтәлек | Көтелгән нәтиҗә | | | Укучылар эшчәнлеге төрләре | Контроль эш төрләре | Үткәрү вакыты план / факт |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | метапредмет | предмет | шәхескә кагылышлы | | | |
| **Башлангыч сыйныфта үткәннәрне кабатлыйбыз, хәтердә яңартабыз** (5с.+ 3с.*) | | | | | | | | | |
| 1. | Дәреслек белән танышабыз. «Туган тел, тынычлык, дуслык» темасына әңгәмә | 1* | | Дәреслек белән танышу барышында уку төрләрен (танышу һәм өйрәнү характерында) куллану; тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; төркемнәрдә эшләү. | Туган телнең кеше һәм җәмгыять тормышындагы әһәмиятен, ролен аңлау; текстның темасын билгеләү, тезисны аңлата белү. | Татар теленең байлыгын, матурлыгын тоярга өйрәнү; туган телне өйрәнүнең әһәмиятен аңлау; үзеңне тыңлаучы күзлегеннән анализлау | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү | | |
| 2. | Лексикология | 2 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; төркемнәрдә эшләү; үз фикереңне төгәл һәм иркле җиткерә белү | Сүз, аның лексик мәгънәсе, туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләр, синоним, антоним, омонимнар төшенчәләрен белү; бирелгән сүзләр белән җөмләләр төзи белү. | Татар теленең байлыгын, матурлыгын тоярга өйрәнү; туган телне өйрәнүнең әһәмиятен аңлау; туган телнең кешенең шәхси сыйфатларын үстерүдәге ролен аңлау | Логик фикер йөртү, гомумиләштерү, системалаштыру, нәтиҗә ясау | Бирем үтәү | |

[1] Укыту-методик тәэмин итү буларак укытучы календарь-тематик планны бирә ала

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3. | Исем, сыйфат, сан, алмашлык, фигыль сүз төркемнәре | 1 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; төркемнәрдә эшләү; үз фикереңне төгәл һәм ирекле җиткерә белү | Исем, сыйфат, сан, алмашлык, фигыль сүз төркемнәре белү; бирелгән сүз төркемнәренә караган сораулар һәм билгеләрне аерып чыгару; сүзләрне төркемнәре буенча аера белү | Татар теленең байлыгын, матурлыгын тоярга өйрәнү; сөйләмне камилләштерүгә омтылу | Логик фикер йөртү, гомумиләштерү, системалаштыру, нәтиҗә ясау | | |
| 4. | Җөмлә | 2 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; төркемнәрдә эшләү; язмадагы мәгълүматның (текстның төп фикерен) дөрес аңлау. | Җөмләнең төп билгеләрен белү; җөмләнең чикләрен аера һәм тыныш билгеләрен куя белү; җөмләнең грамматик нигезен билгели белү; текстның төп фикерен билгеләү | Татар теленең эстетик кыйммәтен аңлау; сөйләмнең сәнгатьлелеген тою | Логик фикер йөртү, гомумиләштерү, системалаштыру, нәтиҗә ясау | Бирем үтәү | |
| 5. | Тикшерү характерындагы диктант | 1* | | Үзконтрольгә сәләтле булу | Сүзләрне дөрес язу; сүзләрне төркеме буенча аеру | Үзбәягә сәләтле булу | Үз-үзеңә контроль ясау | Диктант | |
| 6. | Хаталар өстендә эш. Мәкаләне редакцияләү | 1* | | Үзконтрольгә сәләтле булу. | Текстның темасын һәм төп фикерен билгеләү; төп фикердән һәм терәк сораулардан чыгып, текстны редакцияли белү | Үзбәягә сәләтле булу | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, нәтиҗә ясау | Мәкаләне редакцияләү | |
| **Фонетика (34+12*)** | | | | | | | | | |
| 7. | Фонетика һәм орфоэпия турында гомуми төшенчә | 1 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу | Фонетиканың өйрәнү предметын белү; тел белемөнең фонетика һәм орфоэпиясе турында төшенчә бирә белү; сөйләмнең авазлардан торуын һәм сөйләм авазларының сүзнең мәгънәсен аеруда катнашуын белү; язуда авазларның хәрефләр белән | Телне өйрәнүгә кызыксыну уяту | Төшенчә, термин, кагыйдәләрне аңлап кабул итү, эзләнү таләп итә торган мәсьәләләрне чишү юлларын үзләштерү | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | белдерелүен белү; авазлар һәм хәрефләр турында аңлата белү; транскрипци-яне, аның билгеләрен белү; сүзләрне аваз һәм хәре-фләргә таркатып яза белү | | | | |
| 8. | Сөйләм органнары. Авазларның яса-лышы | 1 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу | Сөйләм процессында кат-наша торган сөйләм орган-нарын белү; сөйләм авазларының ясалышын, авазлар ясалганда сөйләм органнарының ничек кат-нашуын белү; сузык һәм тартык авазларны әйт-кәндә, тавыш ярыларының хезмәтен аңлата алу; телнең авазлар ясауда кат-нашуын аңлата белү; сузык авазларның шаудан, тар-тык авазларның тавыш һәм шаудан яки шаудан гына торуын аңлата белү; текстның төп фикерен формалаштыру; текстка исем бирү, текстка карата бирелгән сорауларга җавап бирә белү. | Телне өйрәнүгә кызыксыну уяту; үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу; бирелгән текстның эчтәлеген язуга кызыксынды-ру | Логик фикер йөртү, анализ, гому-миләштерү, нәтиҗә ясау, тексттан мәгълүмат алу техни-касын камилләштерү | Бирем үтәү | |
| 9. | Сузык һәм тартык авазлар | 1 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; үзеңнең сөйләмеңне камил-ләштерүгә омтылу | Хәзерге татар әдәби те-лендә сузык һәм тартык авазларның санын белү; текстка исем бирү, текстка карата бирелгән сорауларга җавап бирә белү | Телне өйрәнүгә кызыксыну уяту; үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу | Схема буенча логик фикер йөртү, нәтиҗә ясау, тәрҗемә итү | Тәрҗем ә итү | |
| 10. | Сузык авазлар, аларның әйтелеше. | 4 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып | Татар телендәге сузык авазлар, нечкә һәм калын | Татар теленең бай-лыгын, матурлыгын | Схема буенча логик фикер йөртү, нәтиҗә | Ши-гырьне | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Сингармонизм законы | | | алу; орфографик сүзлекчәне куллану, үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу; тексттагы мәгълүматны төркемли белү | сузыклар, кыска һәм озын сузыкларны аерып әйтә белү; *[о], [ы], [э]* һәм *[о¯], [ы¯], [э¯]* авазларының ясалышындагы һәм әйтелешендәге аерманы төшенү;<br>сузыкларның калынлыкта-нечкәлектә ярашулары – сингармонизм законы турында төшенчә бирә белү; рәт гармониясе һәм рәт гармониясе сакланмаган очракларны аңлата белү; сүзләргә кушымчалар ялгану үзенчәлекләрен аңлата белү; иреннәрнең хәрәкәтенә карап, сузыкларның иренләшкән-иренләшмәгән булуын аера белү; татар телендә беренче иҗектә *[а]* авазы *[о]* төсмере белән әйтелүен һәм бу әйтелешнең әдәби тел әйтелеше булуын, ә рус телендәге *[а]* авазының ачык әйтелүен мисаллар белән дәлилли белү; ирен гармониясен аңлата белү, аның язылышта чагылыш тапмавын төшендерә белү; текстның төп фикерен формалаштыру; текстка исем бирү, текстка карата бирелгән сорауларга җавап бирә белү; планга нигезләнеп, хикәя төзеп яза | аңлау; телне өйрәнүгә кызыксыну уяту; үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу; план буенча хикәя төзеп язу эзлеклелеген билгели белү | ясау, тексттан мәгълүмат алу техникасын камилләштерү, нәтиҗә ясау, термин, кагыйдә, закончалыкларны аңлап кабул итү, татар теле һәм рус теле авазларының аермалы якларын таба белү, планга нигезләнеп, хикәя төзеп язуны камилләштерү, рәсемгә карап хикәя язуны камилләштерү | хәтердән язу (54 нче күнегү).<br><br>План буенча хикәя төзеп язу. Рәсемгә карап, хикәя төзеп язу<br><br>Фонетик пропорцияне чишү | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | белү; рәсемгә карап, ирен гармониясенә буйсынган сүзләрне кертеп, хикәя төзи белү; сузык авазларга характеристика бирә белү һәм фонетик пропорцияләрне чишә белү | | | | |
| 11. | Диктант (фонетика буенча) | 1* | | | Дөрес язу күнекмәләрен булдыру. | | Үз-үзеңә контроль ясау | Диктант | |
| 12. | Хаталар өстендә эш. Тартык авазлар, аларның әйтелеше. Тартык авазларның сөйләмдәге үзгәреше | 3 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу; тексттагы мәгълүматны төркемли белү | Яңгырау һәм саңгырау тартыклар, парлы яңгырау һәм парлы саңгырау тартыкларны белү; парсыз яңгырау һәм саңгырау тартыкларны белү; сүздә яңгырау һәм саңгырау тартыкларны аера белү; тартык авазларның яңгырау яки саңгырау булуын тәҗрибә үткәреп, аңлатып бирә белү; тел шомарткычларны дөрес, тиз һәм ачык итеп әйтә белү, авазларны дөрес әйтүдә тел шомарткычларының әһәмиятен аңлата белү; татар һәм рус телләрендә тартыкларның калын яки нечкә әйтелүе нәрсәгә нигезләнгән булуын аңлата белү; үпкәдән килә торган һаваның тоткарлану урынына бәйле тартыкларның ясалу урыны буенча төркемнәрен, шул төркемнәргә нинди авазлар керүен әйтә белү; | Телне өйрәнүгә кызыксыну уяту; үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу | Схема буенча логик фикер йөртү, нәтиҗә ясау, текст нигезендә тәҗрибә үткәрү, татар теле һәм рус теле тартык авазларын чагыштыра белү | Тәҗрибә үткәрү. Фонетик пропорцияне чишү | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | авыз һәм борын тартыкларын аера белү | | | | |
| 13. | Изложение (81 нче күнегү) | 1* | | Укылган әдәби текстны язма формада күрсәтә алу; башлангыч текстның темасыннан чыгып, логик бәйләнешне саклый алу; текстны язганда, татар теленең дөрес язу кагыйдәләрен һәм әдәби нормаларын саклау | Предметны тасвирлаганда, детальләрнең ролен белү; башлангыч текстның планын төзи белү; әдәби текстның эчтәлеген сөйләгәндә структурасын саклау; үз текстныңны төзи белү. | Бирелгән текстның эчтәлеген язуга кызыксыну уяту. | План төзеп изложение язуны камилләштерү | Изложение | |
| 14. | *[къ]* һәм *[к], [гъ]* һәм *[г]* тартык авазлары | 1 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу; тексттагы мәгълүматны төркемли белү | *[къ], [к], [гъ], [г]* авазларының мөстәкыйль аваз булуына һәм аларның ясалыш үзенчәлекләренә төшенү; кече тел *[къ], [гъ]* авазлары кергән сүзләрне дөрес әйтү; рус теленнән алынган сүзләрдә *[к]* авазының әйтелеш үзенчәлеген аңлата белү; татар һәм рус сүзләрендәге тартыклар чиратлашуын мисаллар ярдәмендә аңлата белү; тексттагы, күнегүләрдәге сүзләрдән кече тел һәм тел арты тартыклары кергән сүзләрне аерып әйтә белү | Телне өйрәнүгә кызыксыну уяту; үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу | Дәреслек, схема, текст белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү, эзләнү таләп итә торган мәсьәләләрне үзләштерү, кагыйдә, закончалыкларны аңлап кабул итү | Бирем үтәү | |
| 15. | *[h]* һәм *[х]* тартык авазлары | 1 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; үзеңнең сөйләмеңне камил- | Йоткылык тартыгы *[h]*, кече тел тартыгы *[х]* авазларының мөстәкыйль авазлар булуына һәм аларның яса- | Телне өйрәнүгә кызыксыну уяту; үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә | Дәреслек, сүзлекчә, схема, текст белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү, | Сүзлек диктанты (*[h]* | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | ләштерүгә омтылу | лыш үзенчәлекләренә төшенү; бу авазлар кергән сүзләрне дөрес итеп әйтә белү; *[h], [x]* авазлары кергән сүзләрнең язылышын хәтердә калдыру | омтылу. | эзләнү таләп итә торган мәсьәләләрне үзләштерү, кагыйдә, закончалыкларны аңлап кабул итү | һәм *[x]* тартык авазлары) | |
| 16. | *[w]* һәм *[в]* тартык авазлары | 2 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу | Ирен-ирен *[w]*, ирен-теш *[в]* авазларының мөстәкыйль аваз булуына һәм аларның ясалыш үзенчәлекләренә төшенү; *[w], [в]* авазлары кергән сүзләрне дөрес әйтү; *[в]* авазының алынма сүзләрдә генә булуын белү; *-ау, -әү* кушылмасына беткән сүзләргә тартым кушымчасы ялганганда, тартым кушымчасы алдыннан ирен-ирен *[w]* авазы әйтелүен, ә язуда *в* хәрефе күрсәтелүен мисаллар ярдәмендә аңлата белү; бу авазлар кергән сүзләргә дөрес транскрипция ясый белү. Рус телендәге текстны татарчага тәрҗемә итеп сөйләү | Телне өйрәнүгә кызыксыну уяту; үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу | Дәреслек, схема, текст белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү, эзләнү таләп итә торган мәсьәләләрне үзләштерү, кагыйдә, закончалыкларны аңлап кабул итү, текстны русчадан татарчага тәрҗемә итүне камилләштерү | Текстны дәвам итеп язу (111 нче күнегү) | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 17. | *[н]* һәм *[ң]* тартык авазлары | 2 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; орфографик сүзлекне куллану; үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу | *[н], [ң]* авазларының ясалыш үзенчәлекләренә төшенү һәм аларны дөрес уку, язу. *[ң]* авазының сүз башында килмәвен белү; борын ассимиляциясен белү һәм тексттан борын ассимиляциясенә мисаллар таба белү; *[н]* авазы, *[къ], [к], [гъ], [г]* авазлары алдыннан килгәндә, *[ң]* булып укылуын аңлата белү; ирен ассимиляциясен белү | Телне өйрәнүгә кызыксыну уяту; үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу | Дәреслек, схема, текст белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү, эзләнү таләп итә торган мәсьәләләрне үзләштерү, кагыйдә, закончалыкларны аңлап кабул итү, сүзләргә транскрипция ясауны үзләштерү | Сүзлек диктанты (*[н]* һәм *[ң]* тартык авазлары) | |
| 18. | Контроль изложение (120 нче күнегү) | 2* | | Укылган әдәби текстны язма формада күрсәтә алу; башлангыч текстның темасыннан чыгып, логик бәйләнешне саклый алу; текстны язганда татар теленең дөрес язу кагыйдәләрен һәм әдәби нормаларын саклау | Предметны тасвирлаганда, детальләрнең ролен белү; текстка исем бирү; башлангыч текстның планын төзи белү; әдәби текстның эчтәлеген сөйләгәндә, структурасын саклау; үз текстныңны төзи белү. | Бирелгән текстның эчтәлеген язуга кызыксыну булу. | План төзеп изложение язуны камилләштерү | Изложение | |
| 19. | *[’]* (һәмзә) тартыгы | 1 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу. | *[’]* (һәмзә) тартыгының ясалыш үзенчәлегенә төшенү; бугаз тартыгының язуда *э, ъ, ь* хәрефләре белән язылуын аңлата белү. | Телне өйрәнүгә кызыксыну уяту; үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу; сөйләмдә аерым сүзләрнең дөрес әйтелешен булдырырга омтылу | Схема белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү, | | |
| 20. | Иҗек. “Минем әнием – иң | 2 + 1* | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып | Иҗеккә билгеләмә бирә белү; ачык һәм ябык | Телне өйрәнүгә кызыксыну уяту; | Проблеманы тирәнтен өйрәнү максатыннан | Бирем үтәү. | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | матур әни” (сочинение, 138 нче күнегү) | | | алу | иҗекләр турында белү; татар телендәге иҗек калыплары, рус теленнән кергән иҗек калыплары турында белү; сүзләрне иҗекләргә аерып язу һәм аларның ачык иҗек яки ябык иҗек булуын билгели белү; текстның төп фикерен формалаштыру; текстка исем бирү; бирелгән тексттан төп мәгълүматны аера белү һәм кечкенә хикәя төзеп яза белү | үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу | өлешчә эзләнү, тикшеренү методларын кулланып мөстәкыйль эшчәнлекне оештыру, план төзеп изложение язуны камилләштерү | Сочинение | |
| 21. | Сүзләрне юлдан-юлга күчерү. Изложение “Кечкенә тургайның сәяхәте” (143 нче күнегү) | 1 + 1* | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу | Сүзләрне юлдан-юлга күчерү кагыйдәләрен белү; тексттагы сүзләрне, юлдан-юлга күчерерлек итеп, иҗекләргә таркатып яза белү; иҗек калыпларына туры килә торган сүзләр уйлап, аларны юлдан-юлга күчерерлек итеп, иҗекләргә таркатып яза белү; текстны кыскарту алымнарын белү; текстның төп фикерен формалаштыру; тексттагы һәр абзацка исем бирү; бирелгән тексттан төп мәгълүматны аера белү; план төзи белү; кыска текст төзи белү; изложение яза белү | Телне өйрәнүгә кызыксыну уяту; үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу | Дәреслек белән эш итә белү, биремнәрне үтәгәндә үз эшчәнлегеңне планлаштыра белү, план төзеп изложение язуны камилләштерү | Изложение | |
| 22. | Басым | 2 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; тексттагы | Татар телендә басымның соңгы иҗеккә төшүен белү; сүзгә кушымча ялганганда, | Телне өйрәнүгә кызыксыну уяту; үзеңнең сөйләмеңне | Татар һәм рус сүзләренең басымын куя белү, танып белү | Мөстәкыйль эш | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | мәгълүматны төркемнәргә дөрес урнаштыру | басымның соңгы иҗеккә күчә баруын аңлата белү; татар телендәге басымның рус теле белән чагыштырганда мәгънәгә тәэсире көчле булмавын аңлата белү; татар телендә сүз басымының соңгы иҗеккә төшмәгән очракларын белү; тексттан сүзнең басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләрне таба белү; татар теленә, рус теленнән һәм рус теле аша башка теллӓрдән кергән сүзләрдә, басымның шул телдәгечә куелуын белү; басымсыз *[ы], [э]* сузык авазларының сөйләмдә кыскаруын мисаллар ярдәмендә аңлата белү | камилләштерүгә омтылу | активлыгын арттыру, игътибарлылык һәм кызыксынучанлыкны арттыру | | |
| 23. | Интонация | 1 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу | Әйтү максаты буенча җөмлә төрләрен белү; интонация турында белү; җөмләләрне әйткәндә, тавышның төрлечә хәрәкәтенә карап, җөмлә төрләрен аера белү | Телне өйрәнүгә кызыксыну уяту; үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу | Дәреслек белән эш итә белү, танып белү активлыгын арттыру | | |
| 24. | Диктант | 1* | | | Дөрес язу күнекмәләрен булдыру | | Үз-үзеңә контроль ясау | Диктант | |
| 25. | Хаталар өстендә эш. Графика һәм орфография | 1 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; чит сөйләмне бәяләү | Тел белеменең графика һәм орфографиясе турында төшенчә бирә белү | Телне өйрәнүгә кызыксыну уяту; үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу | Дәреслек белән эш итә белү, термин, кагыйдәне аңлап кабул итү | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 26. | Алфавит | 2 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу | Алфавитның билгеле бер тәртиптә урнашкан барлык хәрефләр җыелмасы булуын белү; татарларда язу тарихын белү; алфавитны төгәл белү; тартык аваз хәрефләренең исемнәрен дөрес әйтә белү; бер үк хәрефтән башланган сүзләрне алфавит тәртибендә яза белү; план буенча укыган китапка бәяләмә яза белү, рус телендәге текстны татар теленә тәрҗемә итә белү. | Телне өйрәнүгә кызыксыну уяту | Дәреслек белән эш итә белү, сүзләргә транскрипция ясауны камилләштерү, рус телендәге текстны татар теленә тәрҗемә итү | Тәрҗемә итү | |
| 27 | Сузык аваз хәрефләре | 2 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; орфографик сүзлекне куллану | Сузык аваз хәрефләрен белү; бер генә авазга билге булган хәрефләрне белү; ике авазга билге булган *о, ы, е* хәрефләре, һәркайсы икешәр авазлар җыелмасын белдергән *е, ю, я* хәрефләренең нинди авазларга билге булуларын, кулланылыш үзенчәлекләрен белү; алынма сүзләрдә е, ё, ю, я хәрефләренең үзенчәлеген аңлата белү; сүздә *[й]* һәм *[о], [ө]* авазларының аерым хәрефләр белән күрсәтелүен белү; *о, ө* хәрефләренең дөрес язылышын белү | Телне өйрәнүгә кызыксыну уяту; үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу | Дәреслек, сүзлекчә, схема, текст белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү, сүзләргә транскрипция ясауны камилләштерү | Бирем үтәү | |
| 28. | Диктант | 1* | | | Дөрес язу күнекмәләрен булдыру | | Үз-үзеңә контроль ясау | Диктант | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 29. | Хаталар өстендә эш. Тартык аваз хәрефләре | 2 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; орфографик сүзлекне куллану; тексттагы мәгълүматны төркемнәргә дөрес урнаштыру | Татар телендә тартык аваз хәрефләрен белү; *к, г, в* хәрефләренең ике авазга билге булып йөрүенә төшенү; сүз һәм иҗек ахырындагы *у, ү* хәрефләренең *[w]* тартык авазын белдерүен мисаллар белән аңлата белү; ъ һәм *ь* хәрефләренең сүзләрдә нинди очракларда язылуын һәм телдәге вазифаларын төшендерү; сүзләрнең дөрес язылышын аңлата белү | Телне өйрәнүгә кызыксыну уяту; үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу | Дәреслек, сүзлекчә, схема, текст белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү, сүзләргә транскрипция ясауны камилләштерү | Сүзлек диктанты (ъ һәм ь хәрефләре) | |
| 30. | Сүзләрне кушып, сызыкча аша һәм аерып язу. Баш һәм юл хәрефләре | 1 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу | Татар орфографиясенең кагыйдәләрен: сүзләрне кушып һәм сызыкча аша язуны, баш һәм юл хәрефләрен куллануны, сүзләрне юлдан-юлга күчерүне белү | Телне өйрәнүгә кызыксыну уяту; үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу | Дәреслек, сүзлекчә, схема, текст белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү, сүзгә транскрипция ясауны камилләштерү | Сүзлек диктанты (кушма һәм парлы сүзләр) | |
| 31. | Фонетик анализ ясау | 1 | | Эшне эзлекле эшләү сәләте; план буенча эшләү | Фонетик анализ ясау тәртибен белү; сүзгә фонетик анализ ясау (телдән һәм язма) | | Сүзгә фонетик анализ ясауны үзләштерү һәм камилләштерү | | |
| 32. | Контроль диктант | 1* | | | Дөрес язу күнекмәләрен булдыру | | Үз-үзеңә контроль ясау | Диктант | |
| 33. | Картина буенча сочинение язу. “Харис Якупов “Канәфер чәчәге. Натюрморт” | 1* | | Визуаль мәгълүматны текстка әйләндерү; картинада тасвирланган күренешләр буенча үз фикереңне дөрес итеп белдерә алу; язма текст төзү; текстта та- | Картинаны аңлау өчен махсус лексика файдалана белү, картинадагы натюрмортны тасвирлау | Үз текстыңны төзүгә кызыксыну булу; сөйләм камиллегенә омтылу; сочинение язу барышында фикерләреңне төгәл | Картина буенча телдән сөйләм һәм язма сөйләм осталыгы, күнекмәләре булдыру | Сочинение | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | тар теленең әдәби тел нормаларын һәм дөрес язу кагыйдәләрен саклау | | һәм ирекле куллану өчен грамматик чаралар һәм сүзлек запасы җитәрлек булу | | | |
| 34. | Белемеңне тикшер. Фонетика, орфоэпия, графика, орфография буенча йомгаклау тесты | 2+1* | | Бирелгән мәгълүматны дөрес аңлау | Фонетика, орфоэпия, графика, орфография бүлекләре буенча тест сорауларына җавап бирү; сүзләргә фонетик анализ һәм транскрипция ясау; сүздәге хәрефләрне дөрес итеп әйтү һәм авазларын дөрес билгеләү; авазларга дөрес характеристика бирү | | Биремнәрне үтәгәндә үз эшчәнлегеңне планлаштыра белү, сүзгә фонетик анализ һәм транскрипция ясауны камилләштерү, авазларга дөрес характеристика бирү | Тест | |
| 35. | Орфографик сүзлек төзибез (проект төзү) | 1* | | Проект эшен башкаруга сәләтлелек; проект эшен башкарганда татар әдәби теленең нормаларын саклау һәм дөрес язу кагыйдәләрен үтәү | «Фонетика, орфоэпия, графика, орфография» бүлекләре буенча белемнәрне гомумиләштерү; сүздәге хаталарны табып, дөрес итеп язу; орфографик сүзлекчә төзи белү | Проект эшен башкаруга кызыксыну булу | Газета-журналлардан сүзләр туплап, сүзлекчә төзи белү, танып белү активлыгын арттыру | Проект төзү | |
| **Лексикология (17 с.+5 с.*)** | | | | | | | | | |
| 36. | Лексикология. Лексика һәм лексикология турында төшенчә | 3 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; сүзнең фикер, хисләрне белдерүдәге ролен аңлау; аңлатмалы сүзлекчәне куллану | Лексикологиянең өйрәнү предметын белү; сүзнең телдәге функциясен, «сүзнең лексик мәгънәсе», «сүзлек составы», «аңлатмалы сүзлек» төшенчәләренең эчтәлеген белү; сүзнең лексик мәгънәсен аңлату юлларын белү; төрле юлларны кулланып, сүзнең лексик мәгънәсен аңлата алу; план | Татар теленең байлыгын, матурлыгын аңлау, туган тел белән горурлану; сөйләмне камилләштерүгә омтылу | Дәреслек, сүзлекчә, схема, таблица белән эш итә белү, тексттан мәгълүмат алу техникасын камилләштерү, текстны русчадан татарчага тәрҗемә итә белү | Тәрҗемә итү. Сүзлек турында язу | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | буенча теләгән сүзлек турында хикәя төзи белү | | | | |
| 37. | Бер һәм күп мәгънәле сүзләр | 1 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; сүзнең фикер, хисләрне белдерүдәге ролен аңлау; аңлатмалы сүзлекчәне куллану; фикереңне төгәл итеп аңлату | «Бер мәгънәле», «күп мәгънәле» төшенчәләренең эчтәлеген белү; аңлатмалы сүзлекчәдә сүзләрнең мәгънәләре бирелешенә төшенү, бер һәм күп мәгънәле сүзләрне аера белү; күп мәгънәле сүзләрнең лексик мәгънәләре арасында уртаклыкны билгели белү | Татар теленең байлыгын, матурлыгын аңлау, туган тел белән горурлану; сүзләрне урынын белеп куллану | Дәреслек, сүзлекчә белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | Хәтердән язу (225 нче күнегү) | |
| 38. | Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре | 1 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; аңлатмалы сүзлекчәне куллану | Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре, аларның аңлатмалы сүзлекчәдә бирелүе, әдәби текстларда күчерелмә мәгънәле сүзләрнең роле турында белү; тексттан күчерелмә мәгънәле сүзләрне табу; сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәсен билгели белү; үз сөйләмеңдә күчерелмә мәгънәле сүзләрне куллану | Татар теленең байлыгын, матурлыгын аңлау, туган тел белән горурлану; сөйләмне камилләштерүгә омтылу | Дәреслек, сүзлекчә белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | Шигырьне хәтердән язу (230 нчы күнегү) | |
| 39. | Синоним. Антоним. Омоним. “Ике ялкау” әкияте | 1+1* | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; телдәге берәмлекләрне стилистик үзенчәлекләрдән чыгып куллану | «Синоним», «антоним», «омоним» төшенчәләренең эчтәлеген, синоним, антонимнарның сөйләмдәге ролен белү, омонимнарны күп мәгънәле сүзләрдән аера белү; төрле максатлардан чыгып, тиешле синонимны куллану; бирелгән сүзләргә синоним, ан- | Татар теленең байлыгын, матурлыгын аңлау; сөйләмне камилләштерүгә омтылу | Дәреслек, сүзлекчә белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү, игътибарлылык һәм кызыксынучанлыкны үстерү | Телдән сөйләм. “Ике ялкау” әкияте | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | тонимнар сайлый белү, аларны җөмләләрдән табу | | | | |
| 40. | Килеп чыгышы ягыннан татар теленең сүзлек составы | 3 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; аңлатмалы сүзлекчәне куллану | Килеп чыгышы ягыннан татар теленең сүзлек составын, татар теленең үз сүзләрен һәм алынмаларны аера белү; алынма сүзләргә хас билгеләрне аера белү; тексттан гомумтөрки һәм алынма сүзләрне табу | Татар теленең байлыгын аңлау; сөйләмне камилләштерүгә омтылу | Дәреслек, сүзлекчә белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү, тексттан мәгълүмат алу техникасын камилләштерү | Бирем үтәү | |
| 41. | Куллану өлкәсе буенча татар теленең сүзлек составы | 1 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; аңлатмалы сүзлекчәне куллану | Кулланылу өлкәсе буенча татар теленең сүзлек составы турында белү; «гомумхалык сүзләре», «һөнәрчелек сүзләре», «диалекталь сүзләр» төшенчәләренең эчтәлеген белү; кулланылышы чикләнгән сүзләрне аеру | Татар теленең байлыгын аңлау; сөйләмне камилләштерүгә омтылу | Татар теленең сүзлек составын кулланылу өлкәсе буенча бәяли белү | “Минем һөнәрне тап” конкурс | |
| 42. | Куллану активлыгы буенча сүзлек составы. Искергән сүзләр | 2 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; аңлатмалы сүзлекчәне куллану | Кулланылыш активлыгы буенча сүзлек составын, «архаизмнар», «тарихи сүзләр» төшенчәләренең эчтәлеген белү; тексттан искергән сүзләрне табу | Татар теленең байлыгын аңлау; сөйләмне камилләштерүгә омтылу | Татар теленең сүзлек составын кулланылу активлыгы буенча бәяли белү | | |
| 43. | Изложение | 2* | | Укылган әдәби текстны язма формада күрсәтә алу; башлангыч текстның темасыннан чыгып, логик бәйләнешне саклый алу; текстны язганда, татар теленең дөрес язу кагыйдәләрен һәм әдәби | Предметны тасвирлаганда, детальләрнең ролен белү; башлангыч текстның планын төзи белү; әдәби текстның эчтәлеген сөйләгәндә структурасын саклау; үз текстыңны төзи белү | Бирелгән текстның эчтәлеген язуга кызыксыну уяту | План төзеп изложение язуны камилләштерү | Изложение | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | нормаларын саклау | | | | | |
| 44. | Яңа сүзләр (неологизмнар) | 1 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; аңлатмалы сүзлекчәне куллану | Яңа сүзләр (неологизмнар) төшенчәсенең эчтәлеген белү; текстлардан неологизмнарны табу, аларның лексик мәгънәләрен аңлату | Татар теленең байлыгын аңлау; сөйләмне камилләштерүгә омтылу | Дәреслек белән эшли белү, танып белү активлыгын үстерү | Мөстәкыйль эш (268 нче күнегү) | |
| 45. | Фразеологизмнар | 2 | | Тексттан фактик мәгълүматны табу | «Фразеологизм», «тотрыклы сүзтезмә» төшенчәләренең эчтәлеген белү; текстлардан фразеологимнарны табу, аларның мәгънәләрен аңлату; фразеологик әйтелмәләрне русчага тәрҗемә итү | Татар теленең байлыгын аңлау; сөйләмне камилләштерүгә омтылу | Дәреслек белән эшли белү, биремнәрне үтәгәндә үз эшчәнлегеңне планлаштыра белү, фразеологик әйтелмәләрне русчага тәрҗемә итә белү | Тәрҗемә итү | |
| 46. | Аңлатмалы диктант | 1* | | | Дөрес язу күнекмәләрен булдыру | | Үз-үзеңә контроль ясау | Аңлатмалы диктант | |
| 47. | Хаталар өстендә эш. Сүзгә лексик анализ ясау | | | План буенча эшләү эзлеклелеген билгеләү күнекмәсен үстерү | Сүзгә лексик анализ ясау тәртибен белү; сүзгә лексик анализ (телдән, язма) ясау | | Сүзгә лексик анализ ясау тәртибен белү | | |
| 48. | Белемеңне тикшер | 1 | | | | | Биремнәрне үтәгәндә үз эшчәнлегеңне планлаштыра белү | | |
| 49. | Сүз турында хикәя (проект төзү) | 1* | | Проект эшен башкаруга сәләтлелек; проект эшен башкарганда татар әдәби теленең нормаларын саклау һәм дөрес язу кагыйдәләрен үтәү | «Лексикология» бүлеге буенча белемнәрне гомумиләштерү | Проект эшен башкаруга кызыксыну уяту | Дәреслек белән эшли белү, игътибарлылык һәм кызыксынучанлыкны үстерү, проектны үтәгәндә үз эшчәнлегеңне планлаштыра белү | Проект төзү | |
| **Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы (16с.+5 с.*)** | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 50 | Сүзнең тамыры һәм кушымчалар | 3 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; телдән сөйләү барышында татар әдәби теленең нормаларын үтәү | Сүз төзелеше һәм ясалышының предметы, «тамыр», «кушымча» төшенчәләренең эчтәлеген белү; сүздә мәгънәле кисәкләрне аера белү; тамырның сүздә төп мәгънә белдерүче кисәк булуын белү; тамырдаш сүзләрне сүзнең төрле формаларыннан аера белү; сүздә тамырны дөрес аера белү һәм тамырдаш сүзләр сайлау; ясагыч һәм мөнәсәбәт белдерә торган кушымчаларны аеру | Сөйләмне камилләштерүгә омтылу | Термин, төшенчә, кагыйдәләрне аңлап кабул итү | Бирем үтәү | |
| 51. | Мөнәсәбәт белдерүче кушымчалар | 1 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; башлангыч текстны телдән сөйләүгә кызыксыну булу; телдән сөйләү барышында татар әдәби теленең нормаларын үтәү | «Мөнәсәбәт белдерә торган кушымчалар» төшенчәсенең эчтәлеген белү; мөнәсәбәт белдерә торган кушымчаларның модальлек һәм бәйләгеч кушымчаларга бүленүен белү; сүздә тамыр һәм кушымчаларны аера белү | Сөйләмне камилләштерүгә омтылу | Термин, төшенчә, кагыйдәләрне аңлап кабул итү, схема белән эшли белү | Бирем үтәү | |
| 52. | Модальлек кушымчалары | 2 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; башлангыч текстны телдән сөйләүгә кызыксыну булу; телдән сөйләү барышында татар әдәби теленең нормаларын үтәү | «Модальлек кушымчалары» төшенчәсенең эчтәлеген белү; исем, сыйфат, сан, фигыльләргә ялгана торган модальлек кушымчаларын белү; сүзләрдә модальлек кушымчаларын аера белү | Сөйләмне камилләштерүгә омтылу | Дәреслек, схема белән эшли белү, логик фикер йөртә белү, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау | Бирем үтәү.<br><br>Мөстәкыйль эш | |
| 53. | Сүзнең нигезе. Та- | 2 | | Тексттан фактик | «Сүзнең нигезе» | Татар теленең бай- | Дәреслек, схема белән | Бирем | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | мыр һәм ясалма сүзләр | | | мәгълүматны аерып алу; бирелгән текстны телдән сөйләүгә кызыксыну булу; телдән сөйләү барышында татар әдәби теленең нормаларын үтәү | төшенчәсенең эчтәлеген белү; тамыр һәм ясалма нигезле сүзләрне аера белү; сүзләрдә нигезне аера белү, бирелгән ясагыч кушымчалар белән сүзләр уйлау | лыгын, матурлыгын аңлау; сөйләмне камилләштерүгә омтылу | эшли белү, логик фикер йөртә белү | үтәү. | |
| 54. | Сүзләрне төзелеше буенча тикшерү | 1 | | План буенча эшләү эзлеклелеген билгели белү | Сүзләрне төзелеше буенча тикшерү тәртибен белү; сүзләрне төзелеше буенча тикшерү (телдән һәм язма) | | Сүзләрне төзелеше буенча тикшерү тәртибен белү | | |
| 55. | Бирелгән тема буенча сочинение язу (“Кызыклы кич” темасына хат язу) | | 1* | Язма текстны төп үзенчәлекләрдән чыгып төзи белү; язма текст төзү барышында татар әдәби теленең нормаларын һәм дөрес язу кагыйдәләрен саклау | Бирелгән тема буенча сочинение язу | Үз текстыңны төзүгә кызыксыну булу; сочинение язу барышында фикерләрне төгәл итеп җиткерү өчен сүзлек запасы һәм грамматик чаралар җитәрлек күләмдә булу. | Телдән сөйләм һәм язма сөйләм осталыгы, күнекмәләре булдыру | Сочинение | |
| 56. | Сүз төзелеше темасы буенча контроль изложение | 2* | | Өйрәнелгән материалны гомумиләштерү; укылган әдәби текстны кыскартып яза белү; текстны кыскартып язу барышында логик бәйләнешне саклау; дөрес язу кагыйдәләрен һәм әдәби тел нормаларын саклау | Текстны кыскарту алымнарын белү; текстның төп фикерен формалаштыру; текстка исем бирү; башлангыч текстта төп мәгълүматны аера белү; кыска текст төзи белү; кыска изложение яза белү | Язылган текст өчен җаваплылык хисе тою; башлангыч текстны кыскартып язуга кызыксыну булу | Фикер йөртү элементлары кертеп, план төзеп изложение язуны камилләштерү | Изложение | |
| 57. | Хаталар өстендә | 1* | | | | | Үз-үзеңә контроль ясау | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | эш | | | | | | | | |
| 58. | Сүз ясалу ысуллары. Ясагыч кушымчалар ялгау | 2 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу | «Сүз ясалу ысуллары», «кушымча ялгау ысулы» төшенчәләренең эчтәлеген белү; ясагыч кушымчалар белән ясалган сүзләрне аера белү, төрле сүз төркемнәре ясый торган кушымчалар белән яңа сүзләр ясау | Татар теленең байлыгын аңлау | Дәреслек белән эшли белү, танып белү активлыгын үстерү | | |
| 59. | Сүзләр кушылу ысулы | 3 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу | «Сүзләрне кушу ысулы», «кушма сүзләр», «парлы сүзләр», «тезмә сүзләр» төшенчәләренең эчтәлеген белү;сүзләр кушылу ысуллары белән ясалган сүзләрне аера белү; сүзләрне кушу ысулы белән яңа сүзләр ясау, тезмә сүзләрнең ирекле сүзтезмәләрдән аермасын аңлау, аерырга өйрәнү | Татар теленең байлыгын, матурлыгын аңлау | Дәреслек белән эшли белү, танып белү активлыгын үстерү | Тәрҗемә итү | |
| 60. | Сүзләрне кыскарту ысулы | 1 | | Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу | «Сүзләрне кыскарту ысулы» төшенчәсенең эчтәлеген белү; сүзләрне кыскарту юллары белән танышу, кыскартылган сүзләрнең ясалышын һәм язылышын истә калдыру | Татар теленең байлыгын аңлау | Дәреслек белән эшли белү, танып белү активлыгын үстерү | | |
| 61. | И.Шишкин «Имәнлек» картинасы буенча сочинение | 1* | | Визуаль мәгълүматны текстка әйләндерү; картинада тасвирланган күренешләр буенча үз фикереңне дөрес итеп белдерә алу; язма | Картинаны аңлау өчен махсус лексика файдалана белү, картинадагы пейзажны тасвирлау | Үз текстыңны төзүгә кызыксыну булу; сөйләм камиллегенә омтылу; сочинение язу барышында фи- | Телдән сөйләм һәм язма сөйләм осталыгы, күнекмәләре булдыру | Сочинение | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | текст төзү; текстта татар теленең әдәби тел нормаларын һәм дөрес язу кагыйдәләрен саклау | | керләреңне төгәл һәм ирекле куллану өчен грамматик чаралар һәм сүзлек запасы җитәрлек булу | | | |
| 62. | Белемеңне тикшер. Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы буенча йомгаклау тесты | 1 | | Бирелгән мәгълүматны дөрес аңлау | «Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы» бүлеге буенча контроль соруларга җавап бирү; сүзләрне төзелеше буенча тикшерү; сүзләрне ясалышы буенча аеру | | Дәреслек белән эшли белү, игътибарлылык һәм кызыксынучанлыкны үстерү, биремнәрне үтәгәндә үз эшчәнлегеңне планлаштыра белү | Тест | |
| **Кабатлау (5с.+3с.*)** | | | | | | | | | |
| 63. | 5 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау | 3 | | Үз фикереңне дәлилли белү; эшеңнең уңышлылыгын билгеләү | «Фонетика», «Лексикология», «Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы» буенча белемнәрне системалаштыру; төп билгеләр буенча татар теленең авазларын классификацияләү; сүзләрнең лексик мәгънәсен билгеләү; сүзләрне төзелеше буенча тикшерү | Укуга кызыксыну уяту; туган телгә хөрмәт хисе тәрбияләү | Дәреслек белән эшли белү, биремнәрне үтәгәндә үз эшчәнлегеңне планлаштыра белү | Бирем үтәү | |
| 64. | «Алтын болын» дигән темага изложение язу | 1* | | Укылган әдәби текстны язма формада күрсәтә алу; башлангыч текстның темасыннан чыгып, логик бәйләнешне саклый алу; текстны язганда, татар теленең дөрес язу кагыйдәләрен һәм әдәби | Предметны тасвирлаганда, детальләрнең ролен белү; башлангыч текстның планын төзи белү; әдәби текстның эчтәлеген сөйләгәндә структурасын саклау; үз текстыңны төзи белү | Бирелгән текстның эчтәлеген язуга кызыксыну уяту | План төзеп изложение язуны камилләштерү | Изложение | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | нормаларын саклау | | | | | |
| 65. | Еллык контроль диктант | 1* | | | Дөрес язу күнекмәләре булдыру | | Үз-үзеңә контроль ясау | Дик-тант | |
| 66. | Орфографик һәм пунктуацион хата-лар өстендә эш (ре-зерв дәрес) | 1* | | | | | | | |
| 67. | Йомгаклау дәресе | 1 | | | Уку елы буенча өйрәнелгән кагыйдәләрне гамәлдә кул-ланырга өйрәнү | | | | |

# РУС ТЕЛЕНДӘ УРТА (ТУЛЫ) ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘПЛӘРЕНЕҢ РУС ТӨРКЕМЕНДӘГЕ 5 НЧЕ СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫ ӨЧЕН ТАТАР ТЕЛЕ БУЕНЧА БЕЛЕМ БИРҮ ПРОГРАММАСЫ

**Дәреслек:** Ягъфәрова Р.Х., Фәтхуллова К.С. Татар Теле. 5 сыйныф: Рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014

## Аңлатма язуы

5 нче сыйныфлар өчен татар теленнән эш программасы Россия Федерациясендәге һәм Татарстан Республикасындагы мәгарифкә кагылышлы хокукый-норматив актларга һәм федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп төзелде:

1. Россия Федерациясенең “Мәгариф турында”гы Законы (Федеральный закон от 29.12.2012 273-ФЗ “Об образовании в Российской Федерации”).
2. Татарстан Республикасының “Мәгариф турында”гы Законы (Закон Республики Татарстан “Об образовании” № 68-ЗРТ от 22 июля 2013 года, статья 8).
3. Россия Федерациясенең “Россия Федерациясе халыктелләре турында”гы 126-ФЗ нчы номерлы Законы (24.07.1998).
4. РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы приказы, 30 нчы август, 2013 нче ел №115 (“Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам – начального общего, основного общего и среднего общего образования”).
5. “Татарстан Республикасының халык телләре турында” Законы (Закон Республики Татарстан от 08.07.1992 № 1560-XII (ред. от 03.03.2012г.) “О государственных языках Республики Татарстан и других языках в Республике Татарстан”).
6. “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы, 2004нче ел, 1нче июль.
7. “2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы”, 2013 нче ел, 25 нче октябрь, 794 нче карар.
8. Төп гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандарты (Россия Мәгариф һәм Фән министрлыгында 2010 нчы елның 17 нче декабрь боерыгы 1897 нче номер белән расланган, РФ Юстиция Министрлыгында 19644 нче регистрацион номеры белән 2011нче елның 1 нче февралендә теркәлгән).
9. Татарстан Республикасында 2012-2020 нче елларда фән һәм мәгариф үсеше турында “Дәүләт программасы”.
10. 2010-2015 нче елларда Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү стратегиясе “Киләчәк” программасы.

5 нче сыйныф өчен "Татар теле " курсының эш программасы Федераль дәүләт белем бирү стандартларының таләпләренә туры китереп, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән “Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теленнән үрнәк программа”, (төзүче-авторлары: Хәйдәрова Р.З., Фәтхуллова К.С., Җәүһәрова Ф.Х. – Казан, 2013), 5 нче сыйныф өчен Ягъфәрова Р.Х., Фәтхуллова К.С.

тарафыннан эшләнгән (Казан: Татар. кит. нәшр., 2014.) Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән уку әсбабына нигезләнеп төзелде.

Дәреслек: Татар теле. 5 сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014.

**Рус телендә сөйләшүче балаларга та тар теле укытуның төп максаты**

Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә һәм чит телләрдә иркен аралаша алырлык билингваль, полилингваль шәхес тәрбияләү. Татарстан Республикасы Конституциясенең 8 нче маддәсендә һәм “Татарстан Республикасы халыкларының телләре турындагы” Законда күрсәтелгәнчә,Татарстанда дәүләт телләренең икесен дә белү милләтләрнең үзара аңлашып, тату яшәвенең нигезен тәшкил итә.

**Бурычлары:**

- укучыларның аралашу даирәсен, аралашу ситуацияләрен исәпкә алып, сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре (тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу) буенча укучыларда *коммуникатив компетенция (аралашу осталыгы)*формалаштыру; укучының танып белү, гомуми уку күнекмәләрен, сөйләм культурасын үстерү; татар милләтенә, аның тарихи һәм мәдәни хәзинәләренә карата хөрмәт тәрбияләү;
- укучыларны мәдәниятара диалогка тарту; татар телен дәүләт теле буларак өйрәнүгә ихтыяҗ тудыру;
- башлангыч гомуми белем бирү баскычы программасы белән дәвамчанлыкны саклау;
- укыту процессы коммуникатив методның төп принципларын исәпкә алып оештыру: *аралашуга аралашу аша өйрәтү принцибы* (телгә өйрәтү шартларын тормышта телне куллану шартларына якынлаштыру); *шәхси индивидуальләштерү принцибы* (укыту процессын укучыларның шәхси ихтыяҗларын, теләк-омтылышларын, индивидуаль-психик үзенчәлекләрен исәпкә алып оештыру); *телне актив фикерләү нигезендә өйрәнү принцибы* (аралашу ситуацияләрендә сөйләм бурычына тәңгәл килгән лексик-грамматик материалны укучыларның мөстәкыйль куллануын тәэмин итү); *телне функциональ төстә өйрәнү принцибы* (лексик-грамматик материалның коммуникатив максаттан, аралашу ихтыяҗыннан һәм куллану ешлыгыннан чыгып билгеләнүе);
- *ана телен исәпкә алу принцибы* (балаларның ана теле буенча белемнәр системасын исәпкә алу;
- рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен укытуны аларның коммуникатив культурасын үстерүгә юнәлтү.

**Белем дәрәҗәсенә таләпләр:**

- татар теленең төп фонетик үзенчәлекләрен гамәли белү;
- татар теленә генә хас фонемаларны дөрес әйтә белү, сөйләмдә дөрес әйтү;
- татар телендәге сүз ясалыш ысулларын үзләштерү, гамәли куллану;
- сүз басымын дөрес куюга ирешү;
- һәр сүз төркеменең сөйләмдә дөрес һәм урынлы кулланылышын үзләштерү;
- аралашканда лексик-грамматик нормаларны саклап, сораулар бирә белү һәм җавап кайтара алу;
- диалогик сөйләмдә орфоэпик, лексик-грамматик нормаларны саклап, сөйләм яңалыгын җиткерә, үз фикереңне дәлилли белү;
- тәкъдим ителгән ситуация буенча сөйләшү үткәрү;

- тәкъдим ителгән ситуациягә карата фикерне язмача оештыра белү.

**Күнекмәләргә таләпләр**:

Гомуми белем мәктәбендә татар теле дәресләре укучыларның сөйләм телен үстерүгә юнәлтелә, бу исә аларның **тыңлап аңлау, сөйләү һәм сөйләшү, уку, язу һәм язма сөйләм күнекмәләрен формалаштыруны** үз эченә ала.

- **Тыңлап аңлау** – аерым авазларны, иҗек калыпларын, сүзләр, сүзтезмәләр, җөмләләрне, бәйләнешле текстларны ишетеп, мәгънәләрен һәм эчтәлекләрен аңларга өйрәтү.
- **Диалогик сөйләмгә өйрәткәндә**, укучыларны чынбарлыктагы ситуацияләргә куеп карау кирәк. Татарча аралашырга өйрәтү өчен, укучыларның мәктәптәге, өйдәге, урамдагы һәм җәмәгать урыннарындагы көндәлек тормышыннан чыгып, үрнәк диалоглар тәкъдим ителә.
- **Монологик сөйләмгә өйрәтү** аерым кешеләрне, әйберләрне табигать күренешләрен, хайваннарны тасвирлауга, сыйныф, мәктәп, авыл, шәһәр тормышы һ. б. турында хәбәр итүгә, укылган (тыңланган) текстның эчтәлеген план буенча сөйләп бирүгә кайтып кала.
- **Укуга өйрәткәндә**, рус телле балалар татар хәрефләрен танып, алар белдергән авазларны дөрес әйтергә; алга таба сәнгатьле итеп, йөгерек һәм аңлап укырга, яңа сүзләрне сүзлектән табарга өйрәтү максаты куела.
- **Язуга өйрәтү** татар алфавитындагы хәрефләрнең дөрес язылышын истә калдыру; сүзләрне иҗекләргә бүлеп, юлдан юлга дөрес күчерү кагыйдәләрен үзләштерү; сөйләмдә актив кулланыла торган сүзләрне орфографик дөрес язу күнекмәләрен үстерү; нокталар урынына кирәкле сүзләрне куеп яки җәяләр эчендә бирелгән сүзләрне кирәкле формада кулланып, җөмләләрне күчереп язу.
- **Язма сөйләмгә өйрәтү**, терәк сүзләр, сүзтезмәләр һәм үрнәк җөмләләргә нигезләнеп, өйрәнелә торган лексик тема яки бирелгән ситуация буенча җөмләләр яза белү. Укучылар язма рәвештә үзләренең гаиләләре, мәктәпләре, сыйныфташлары һәм дуслары, яшәгән шәһәрләре яки авыл турында кечкенә күләмле хикәяләр язарга өйрәнәләр. Рус теленнән татарчага тәрҗемә итү дә язма сөйләм күнекмәләрен камилләштерүгә китерә. Укучыларның уку һәм язу күнекмәләре тыңлап аңлау һәм сөйләү нигезендә үстерелә.
- Укучыларда **фонетик күнекмәләр** булдыру өчен, түбәндәгеләргә игътибар итү мөһим: татар теленә генә хас булган авазларның әйтелешен үзләштерү; татар һәм рус телләрендә уртак булган, ләкин әйтелешләре белән аерылган авазларны чагыштырып өйрәнү; авазларны сүзләрдә, сүзтезмәләрдә, җөмләләрдә, бәйләнешле сөйләмдә дөрес әйтүгә ирешү. Бу төр күнекмәләр булдыру өстендә эзлекле эшләү генә укучыларның сөйләмендәге фонетик хаталарны бетерергә мөмкинлек бирә.
- Укучыларның **лексик күнекмәләрен** үстерү өчен, сүзләрнең әйтелешен, язылышын, мәгънәсен, ясалышын, башка сүзләр белән бәйләнешен, сөйләмдә кулланышын үзләштерү шарт. Моның белән беррәттән, татар һәм рус сүзләрнең мәгънә ягыннан аермаларын күрсәтеп бару да, рус телендә эквивалентлары булмаган сүзләрне аңлатып бирү дә сорала.
- Укучыларның **грамматик күнекмәләрен** үстерү – төрле сүз төркемнәренең морфологик формалары, ясалышлары белән таныштыру, сүзләрнең җөмләдә үзара бәйләнеш чараларын үзләштерү һәм кагыйдәләрен белү дигән сүз. Татар телен икенче тел буларак укытканда, лексик-грамматик материалны синтаксик нигездә

үзләштерү принцибына таянып эш итү кирәк, чөнки сүзләр башка сүзләр белән бәйләнештә булганда гына, җөмлә, гомумән, сөйләм барлыкка килә.

**Уку фәненең уку планында тоткан урыны**

5 нче сыйныфта телне гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда татар теленең күп мәдәниятле дөньядагы роле һәм мөһимлеге турында күзаллаулар формалаша. Татар мәдәниятенең укучылар өчен булган катламы белән танышу башка мәдәниятләргә карата ихтирам хисе уята, укучыларга үз мәдәниятләрен дә тирәнрәк аңларга һәм объектив бәяләргә мөмкинлек бирә.

Укыту планында каралганча, татар теле дәресләре өчен эш программасы атнага 3 сәгать исәбеннән, елга 102 сәгатькә төзелде.

**Укытуның көтелгән нәтиҗәләре**

**Шәхскә кагылышлы нәтиҗәләр**:

- шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы булу һәм аны яхшы өйрәнергә теләү;
- туган илеңнең, туган ягыңның тарихын, анда яшәүче халыкларның мәдәниятен һәм сәнгатен белү;
- укуга, үзлегеңнән белем алуга җаваплы карау;
- әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
- *гаилә, туган ил* төшенчәләрен кабул итү, башкаларга карата түземле һәм кайгыртучан, ихтирамлы булу;
- үз-үзеңне эстетик яктан тәрбияләү;
- башкаларны тыңлый һәм аңлый белү, итагатьле әңгәмәдәш булу, үзара аңлашуга ирешү;
- белем алу һәм башка эшчәнлек барышында үз яшьтәшләре, өлкәннәр белән мөнәсәбәт урнаштыра һәм аралаша белү;

**Предметара нәтиҗәләре:**

Татар теле, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган укуның универсаль гамәлләрен (***танып белү, регулятив, коммуникатив)*** формалаштыруга хезмәт итә.

Предметара универсаль уку гамәлләре татар телен өйрәнү күнекмәләрен чит телләрне өйрәнүгә, чит телләрне өйрәнү гамәлләрен татар телен өйрәнүгә, аларның икесен дә үз ана телләрен тирәнрәк өйрәнүгә этәргеч булып тора.

Укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар текст, күрмә-график символлар, хәрәкәтле яисә хәрәкәтсез сурәтләр, ягъни төрле коммуникацион технологияләр аша тапшырыла торган мәгълүмати объектлар белән эшләү тәҗрибәсе ала; презентацияләр әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрән*ә; у*кучыларда, компьютер яисә ИКТ нең башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алу күнекмәләре формалаша.

**Танып белү нәтиҗәләре**:

- фикер йөртү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәпле-нәтиҗәле бәйләнешләрне табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
- иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү алгоритмнарын мөстәкыйль төзи алу;

- объектларны чагыштыру нигезендә уртак билгеләрне күрсәтү;
- төп һәм икенчел мәгълүматларны аеру, укылган яки тыңланган эчтәлеккә бәя бирә белү;
- тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.

**Регулятив нәтиҗәләр:**

- уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели алу;
- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыру, нәтиҗәле эш алымнарын табу;
- уку эшчәнлеге барышын, нәтиҗәләрен тикшереп бару һәи кирәкле төзәтмәләр кертү;
- укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләргә ия булу;
- дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белү;
- дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерләү һәм тәртиптә тоту.

**Коммуникатив нәтиҗәләр:**

- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
- әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;
- аралаша белү сәләтенә ия булу;
- парларда һәм күмәк эшли белү;
- мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;
- әңгәмәдәш белән сөйләшүне башлау, дәвам иттерү, уңышлы тәмамлау.

Татар теленә өйрәтүнең **предмет нәтиҗәләре**:

**Сөйләү**

- сорау һәм җавап репликаларын дөрес кулланып, тәкъдим ителгән ситуация буенча диалог оештыру (һәр укучының репликалар саны 7 дән ким булмаска тиеш);
- укылган яки тыңланган текстның эчтәлеге буенча әңгәмә кору;
- җыйнак җөмләләрне җәенкеләндереп, хикәя төзү;
- лексик тема буенча бәйләнешле текст төзеп сөйләү (җөмләләр саны 8дән ким булмаска тиеш);
- укылган (тыңланган) текстның эчтәлеген сөйләгәндә, төрле җөмлә калыпларын урынлы куллану һәм фикерне эзлекле белдерү.

**Тыңлап аңлау**

- 1 минутлык бәйләнешле текстны тыңлап, аның буенча сорауларга җавап бирү; эчтәлеген аңлау;
- дәрестә катнашучыларның җанлы сөйләмен тыңлап, эчтәлегенә төшенү.

**Уку**

- төрле жанрлардагы текстларны сәнгатьле итеп һәм тулысынча аңлап уку һәм төп фикерне табып әйтү;
- тексттагы таныш булмаган сүзләрнең мәгънәләрен сүзлекләрдән табып аңлату; контекстка таянып, мәгънәсенә төшенү;
- шигырьләрне яттан сөйләү.

**Язу**

- сүзлек диктантлары язу;
- лексик тема буенча хикәя язу;
- - укылган (тыңланган) текстның эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар язу;
- җөмләләрне, бәйләнешле текстны үзгәрешләр кертеп язу.

**Тел чаралары һәм аларны куллану күнекмәләре**

- татар сөйләмен фонетик яктан дөрес оештыру;
- үзенчәлекле авазлы сүзләрне дөрес әйтү;
- аерым сүзләрдә, фразада басымны дөрес кую;
- әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләрен аеру;
- ритм һәм интонация үзенчәлекләрен исәпкә алып, җөмләләрне дөрес әйтү;
- актив үзләштерелгән сүзләрне дөрес язу.
- аралашу барышында, коммуникатив максаттан чыгып, актив лексикадан файдалану;
- өйрәнелгән аралашу темаларына караган лексик берәмлекләрне һәм сүзтезмәләрне тану.
- өйрәнелгән грамматик формаларны сөйләмдә дөрес куллану һәм тексттан табып әйтү;
- җөмләнең төп коммуникатив төрләрен сөйләмдә куллану.

**Сөйләмнең предмет эчтәлеге**

Телдән һәм язма сөйләмнең эчтәлеге белем һәм тәрбия бирү максатларыннан, шулай ук укучыларының яшь үзенчәлекләре һәм мәнфәгатьләреннән чыгып билгеләнә:

*Яңа уку елы белән! (11 сәгать)*

*Кеше һәм сәламәтлек (11 сәгать)*

*Өйдә һәм кунакта (10 сәгать).*

*Туган ягыбызның табигате (10 сәгать).*

*Татарстан Республикасы (10 сәгать).*

*Уйныйбыз да, биибез дә (10 сәгать).*

*Һөнәрләр дөньясында (10 сәгать).*

*Музейлар һәм театрлар (10 сәгать).*

*Сәяхәт итү (10 сәгать).*

*Бигрәк матур җәй! (10 сәгать).*

**Тел материалы**

*Фонетика*. Лексик темаларга караган сүзләрнең әйтелеше һәм язылышы. Әйтелеше белән язылышы арасында аерма булган сүзләр. Татар һәм рус телләрендә сүз басымы.

*Лексика.*Аралашу темаларына караган лексик берәмлекләрне рецептив һәм продуктив рәвештә үзләштерү. Гади тотрыклы гыйбарәләр; сөйләм әдәбе берәмлекләре. Алынма сүзләр (мәсәлән, *музей, театр*). Актив үзләштерелгән сүзләрнең синонимнары, антонимнары. Сүз ясагыч кушымчалар: *-даш/-дәш, -таш/-тәш (сыйныфташ, юлдаш).*

*Морфология һәм синтаксис.* Сан, тартым белән төрләнгән исемнәргә килеш кушымчалары ялгану тәртибе (*апа + лар + ым + ны; дәф + тәр + ләр + егез + гә).* Зат алмашлыкларын җөмлә төзүдә куллану үзенчәлекләре: (*Бу — абыем.* ***Аның*** *исеме — Марат.* ***Бу — безнең*** *мәктәп. Ул яңа.* ***Без аны*** *яратабыз*). Берлек һәм күплек сандагы тартымлы исемнәр. Тартым кушымчасының рус теленә тәрҗемә итү үзенчәлекләре. Инфинитив формасындагы фигыльнең модаль сүзләр белән кулланылышы: *барырга кирәк (кирәкми), алырга ярый (ярамый), сөйләргә тиеш (+түгел).* Хикәя фигыльнең өйрәнелгән заман формалары. Билгесез киләчәк заман хикәя фигыльнең барлыкта-юклыкта зат-сан белән төрләнеше. *Буенда, буйлап, буенча* бәйлек сүзләре. *Бәлки, билгеле, димәк, беренчедән, икенчедән, минемчә, синеңчә* кереш сүзләре. Кушма *(башваткыч, тизәйткеч, урынбасар),* парлы *(бала-чага)* һәм тезмә (*бака яфрагы*) исемнәр. Җөмләнең баш кисәкләре. Хикәя, боеру, сорау җөмләләрдә сүз тәртибе. Җөмлә калыплары.

## Тематик планлаштыру

| Төп темалар, сәгатьләр саны | Тема буенча предмет нәтиҗәсе, коммуникатив максат |
|---|---|
| **Яңа уку елы белән!** (11 сәгать)<br>Беренче сентябрь – Белем бәйрәме. Җәйге ялны үткәрү. Дәресләр расписаниесе, дәресләр әзерләү, өй эше эшләү. Билгеләр. Уку-язу әсбаплары, аларны тәртиптә, саклап тоту. Китапханәдә | Беренче сентябрь - Белем бәйрәме турында сөйли белү. Җәйге ялны ничек үткәрү турында сөйләшү. Дәресләр расписаниесе буенча нәрсә эшләгәнне әйтә белү. Өй эшен әзерләү, әзерләмәүнең сәбәбен әйтә белү. Ни өчен яхшы, начар билгеләр алу турында сөйләшү. Уку-язу әсбаплары, аларны саклап тоту турында киңәш бирә белү. Китапханәчедән кирәкле китапларны сорап ала белү. |
| **Кеше һәм сәламәтлек (11 сәгать)**<br>Көндәлек режим. Тән әгъзалары. Табибта. Сәламәт булу кагыйдәләре. Спорт белән шөгыльләнү | Үзеңнең көндәлек режимың турында сөйли белү. Тән әгъзаларының исемнәрен, нәрсә авыртуын, авыртмавын табибка әйтә, сорый белү. Спорт төрләрен аера, үзеңнең нинди спорт төрен яратканыңны, нинди спорт түгәрәгенә йөргәнеңне, физкультура дәресендә нәрсә эшләгәнеңне әйтә белү.<br>Вакытны сорый, әйтә белү. Өйдә эшләгән эшләрне әйтә, сорый, куша белү. Эш эшләргә риза булуыңны, булмавыңны белдерү. Өй эшләрендә үзеңә булышырга, ярдәм итәргә сорый, нәрсә эшләргә кирәк икәнен әйтә белү. Кибеткә барырга куша, нәрсә алырга икәнен әйтә, сорый белү. Өйдәге эшләрне эшләргә киңәш бирә, яхшы эшләр өчен мактый белү. Өйдәге хезмәттә катнашуга карап, кешеләргә бәя бирә белү. |
| **Өйдә һәм кунакта (10 сәгать).**<br>Без әти-әнигә булышабыз. Өйдәге эшләр. Без бергә эшлибез. Өй хезмәте өчен рәхмәт белдерү һәм мактау. Табын әзерләү. Табын янында үз-үзеңне тоту.Кунакларны чакыру, сыйлау. Гафу үтенү | Өйдә эшләгән эшләрне әйтә, сорый, куша белү. Эш эшләргә риза булуыңны, булмавыңны белдерү. Өй эшләрендә үзеңә булышырга, ярдәм итәргә сорый, нәрсә эшләргә кирәк икәнен әйтә белү. Кунакларны чакыра һәм сыйлау репликаларын белү, дөрес куллану. Табын әзерләү турында сөйләшү. Табын янында үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен сөйли белү.Сөйләм этикеты сүзләрен урынлы куллана белү |
| **Туган ягыбызның табигате (10 сәгать).**<br>Кош исемнәре, аларга хас булган үзенчәлекләр. Үсемлекләр, аларга хас булган билгеләр. Туган як табигатен тасвирлау | Кошларның исемнәрен үзләштерү. Алар турында сөйли белү. Үсемлекләр турында сөйли белү. Туган як табигатен тасвирлап сөйли белү, тиешле сыйфатларны куллану. Табигатьтәге гүзәллеккә, нәфислеккә соклануны чагылдыра бел |
| **Татарстан Республикасы (10 сәгать).**<br>Татарстан күпмилләтле республика. Төрле милләт вәкилләре үзара дус яшиләр. Татарстанда җитештерелә торган продукция күп төрле | Татарстан халкы, аларның үзара мөнәсәбәтләрен чагылдырып сөйли белү. Республикада авыл хуҗалыгы үсеше турында сөйләшә белү. Татарстанда төрле товарлар җитештерелүе турында сөйләү. Республиканың танылган кешеләре турында хикәя төзү |
| **Уйныйбыз да, биибез дә (10 сәгать).**<br>Сабантуй. Милли уеннар, аларның атамалары. Уеннарда катнашу.Тәбрик итү | Сабантуйдагы милли уеннарны әйтә, Сабантуйга бару, катнашу турында сөйләшү. Бәйрәмгә чакыра белү. Бәйрәм белән тәбрик итә белү |
| **Һөнәрләр дөньясында (10 сәгать).**<br>Һөнәр атамалары. Барлык һөнрләр дә мактаулы. Якыннар, аларның һөнәрләре | Төрле һөнәрләр турында диалогик сөйләм оештыра белү. Китапханәче һөнәре турында сөйләшү. Остаханәдә эшләүче рәссам, кульязмалар белән эшләүче тарихчы, янгын сүндерүче, игенче, терлекче һөнәре белән иптәшеңне таныштыра белү. Гаиләгездәге һөнәрләр турында сөйли белү |
| **Музейлар һәм театрлар (10 сәгать).** | Музейга, театрга баруың яки баруыгыз турында берничә җөмләдән торган хикәя төеп сөйли белү. |

| | |
|---|---|
| Казан – музейлар һәм театрлар шәһәре.<br>Музейларның, театрларның атамалары, үзенчәлекле яклары.Тарихны чагылдыра. Борынгы әйберләр. Милли киемнәр | Тема буенча диалог төзү. Казан шәһәрендәге музей һәм театрларның исемнәрен тулы һәм дөрес атау. Музейларның үзенчәлекле якларын чагылдыра, тасвирлый белү |
| **Сәяхәт итү (10 сәгать).**<br>Сәяхәт итү. Чит илләргә бару турында хыял. Билет алу. Тимер юл вокзалында. Елга портында. Диңгездә. Чит ил. Телләр. Ял йорты | Сәяхәт итү турындагы хыялыңны белдерә белү. Кая да булса булган сәяхәт турында кечкенә хикәя төзеп сөйләү. Елга портында һәм тимер юл вокзалында булырга мөмкин булган сөйләшү. Чит илләргә сәяхәт турында сөйләшү. Диңгезгә сәяхәт турында сөйләшү |
| **Бигрәк матур җәй! (10 сәгать).**<br>Җәйге көн. Елга буе, андагы табигать. Су коену. Балык тоту. Ситуациягә карата үз фикереңне белдерү | Җәйге һава торышын чагылдыра белү. Җәйге ялны оештыру турында кечкенә хикәя төзеп сөйләү.Диалог төзү: су коену, балык тоту. Киңәшләр бирә белү, үз фикереңне чагылдыру |

**Белем бирүне материаль-техник һәм мәгълүмати яктан тәэмин итү**

Татар теленә өйрәткәндә, түбәндәге материаль-техник чаралардан файдалану тәкъдим ителә: күрсәтмә әсбаплар; белешмә материаллар; аудио- һәм видеоәсбаплар; мультимедиа технологияләре; компьютер программалары; интерактив тикшерү программалары; татар сайтлары; электрон китапханә; лингафон кабинет.

**Интернет ресурслары:**

http://www.belem.ru

http://kitap.net.ru

Онлайн курс татарского языка «Татарский язык для всех»: http://**tatarile.org**

Онлайн школа EF-АНА ТЕЛЕ: http:// **anatele.ef.com.**

**Кушымта**

## Календарь-тематик план[1]

| Дәрес № | Дәрес темасы | Дәрес саны | Төп эчтәлек | Көтелгән нәтиҗә | | | Укучылар эшчәнлеге төрләре | Контроль эш төрләре | Үткәрү вакыты план / факт |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | шәхси | метапредмет | предмет | | | |
| **Яңа уку елы котлы булсын! – 11 сәг.** | | | | | | | | | |
| 1 | Сузык авазлар. Җөмләинтонациясе. Белем көне. | 1 | Татар теленең сузык авазларын кабатлау, интонация төрләрен искә төшерү. Җөмлә калыпларын диалогик һәм монологик сөйләмдә дөрес кулланунга ирешү. Белем көне турында сөйләшү. | Үзең укыган мәктәбеңне, укытучыларыңны хөрмәт итү. | Татар һәм рус алфавитларын, ике телдәге сузык авазларны чагыштыра белү. | Сүзләрдә авазларны, сөйләмдә интонацион калыпларны, дөрес әйтә белү. | Җәйге ял турында әңгәмә кору; диалогны уку һәм сорауларга җавап бирү; җөмләләр төзеп язу; яңа сүзләрне дөрес әйтү. | Белем бәйрәме турында сөйләү. | |
| 2 | Калын һәм нечкә сузыклар.Татар теле дәресләре. | 1 | Татар телендәге сузык авазларның төрләрен, аларның нинди хәрефләр белән билгеләнүен гамәли үзләштерү. Төрле дәресләр турында сөйләшү. | Татар теленә карата ихтирамлы булу. | Калын һәм нечкә сузыкларны рус телендәге авазлар белән чагыштырып, аермасын билгели алу. | [а], [ә],[ө], [ү], [и], [ы] авазларын сөйләмдә дөрес әйтә белү. | Диалогны уку; сораулар куеп, җөмләләрне уку; тизәйткеч өйрәнү. | Фронталь әңгәмә, диалогны яттан сөйләү. | |
| 3 | Авазлар һәм хәрефләр. Сүзләрнең калын яки нечкә әйтелеше. Безнең сыйныф. | 1 | Татар алфавитындагы хәрефләрне һәм алар белдергән авазларны искә төшерү, сүзләрнең калын һәм нечкә әйтелешен бил- | Уку эшчәнлеген мөстәкыйль оештыра алу. Парлап һәм төркемдә эшли белү. | Рус алфавитына өстәлгән татар хәрефләрен белү. Дәресләрдә активлык | Сөйләмне фонетик һәм лексик яктан дөрес оештырабелү. | Диалогны уку һәм тәрҗемә итү; диалог төзү; җөмләләрне дәвам итеп уку; шигырь өйрәнү. | Сорауларга язмача җавап бирү. | |

[1] Укыту-методик тәэмин итү буларак укытучы календарь-тематик планны бирә ала

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | геләү. Сыйныф тормышы турында сөйләшү. | | күрсәтү. | | | | |
| 4 | [а],[ә] сузыклары. Уку көне. | 1 | [а ], [ ә] сузыкларның әйтелешен аңлату, транскрипция билгеләре белән таныштыру. Уку көнен үткәрү турында фикер алышу. | Көндәлек режимның сәламәтлеккә йогынтысын аңлау. | Коммуникатив бурычны куя һәм хәл итә белү. | Көндәлек режим турында мөстәкыйль сөйләшү оештыра алу. Өйрәнелгән тел материалын сөйләмдә дөрес куллану. | Бирелгән үрнәккә таянып, охшаш диалог төзү; сөйләм репликаларын әйтү; җөмләләрне дәвам итеп язу; шигырь өйрәнү. | Коммуникатив биремнәр. | |
| 5 | [о] сузыгы. Дусларым-сыйныфташларым. | 1 | [о] сузыгының үзенчәлеген һәм рус сүзләрендәге аермасын аңлату. Укучыларның монологик һәм диалогик сөйләм күнекмәләрен үстерү. | Дусларга карата ихтирамлы булу. | Дәрес барышында үз нәтиҗәләреңне тикшереп бару һәм сөйләмгә төзәтмәләр кертә алу. | [о] сузыгын аерым сүзләрдә, җөмләдә дөрес әйтү. Дуслар турында сөйли белү. | Сүзләрне тыңлау һәм укытучы артыннан кабатлау; җөмләләргә сораулар куеп уку; текстны уку һәм үрнәк буенча якын дуслар турында сөйләү; һава торышы һәм үсемлекләр турында диалоглар төзү; боерык фигыльләрне истә калдыру. | Сүзлек диктанты. | |
| 6 | [ө] сузыгы. Көндәлек тормыш. | 1 | [ө] сузыгының әйтелеш үзенчәлекләрен аңлату. Сорау –җавап репликаларын дөрес кулланырга өйрәтү. | Сыйныфташларның җавабын тыңлый белү. | [ө] авазлы сүзләр ярдәмендә мәктәп тормышы һәм табигать турында фикер йөртә белү. | [ө] сузыклы сүзләрне телдән һәм язма сөйләмдә дөрес куллана белү. | Кирәкле сүзләрне куеп, җөмләләрне уку; җөмләләрне дәвам итеп уку; рәсемнәргә карап, сорауга җавап бирү; *өй* сүзен төрле килешләрдә куеп, җөмләләрне уку; дөрес җавапны табып әйтү. | Фронталь әңгәмә,сорауларга телдән җавап бирү. | |
| 7 | [ы] авазы. Хәзер- | 1 | [ы] сузыгының әйте- | Дәерсләрдә кызык- | Укытучы һәм | [ы] сузыгы | Диалогны уку; сора- | Хикәя | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ге заман хикәя фигыль. Татар теле дәресләре. | | леш үзенчәлекләрен аңлату. [ы] авазлы сыйфатларны һәм хикәя фигыльләрне сөйләмдә кулланырга күнектерү. Монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү. | сынучан булу. | сыйныфташлар белән аралаша белү сәләтенә ия булу. | авазлы сүзләрне дөрес әйтә һәм монологик сөйләмдә кул-лана белү. | уларга телдән җавап бирү; кирәкле фигыльләрне кулла-нып, җөмләләрне дәвам итеп язу; та-бышмакның җавабын әйтү. | төзеп сөйләү. | |
| 8 | [э] авазы. Бил-геләү алмаш-лыклары. | 1 | [э] сузыгының әйте-леш үзенчәлекләрен, нинди хәрефләр белән белдерелүен аңлату. Килеш кушымчала-рын кабатлау. Диало-гик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен ныгыту. | Йорт хайваннарына мәрхәмәтле булу. | Авазларны ча-гыштыру ниге-зендә уртак билгеләрне күрсәтү. Пар-ларда эшли белү. | [э] авазлы сүзләрне дөрес әйтү, килеш кушымчаларын дөрес ялгау, җавап реплика-ларын куллана белү. | Сүзләрне күмәк рәвештә әйтү һәм истә калдыру; яңа сүзләр белән җөмләләрне уку һәм тәрҗемә итү; кирәкле кушымчаларны куеп, җөмләләрне уку; парлап диалоглар төзү; шигырь уку һәм эчтәлеген сөйләү. | Фронталь әңгәмә. Телдән сөйләмне тикшерү. | |
| 9 | [у] авазы. Боерык фигыль. Ел фа-сыллары. | 1 | [у] авазлы сүзләрнең әйтелеш үзенчәлек-ләрен аңлату, боерык фигыльләрне ка-батлау, укылган текстның эчтәлеге буенча фикер алышу. | Төрле ел фасылла-рындагы матурлык-ка соклана белү. | Әңгәмәдәшеңне ң фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү. | [у] сузыклы сүзләрне дөрес әйтү, текстны сәнгатьле итеп һәм тулысынча аңлап уку һәм сорауларга телдән җавап бирү. | Боерык фигыльле җөмләләрне татарча әйтү; текст уку һәм эчтәлеге буенча со-рауларга җавап бирү; *чонки* теркәгечле җөмләләр төзеп уку; шигырь өйрәнү. | Сүзлек диктанты | |
| 10 | [ү] авазы. Тар-тымлы исемнәрне кабатлау. | 1 | [ү ] авазлы сүзләрнең әйтелеш үзенчәлек-ләрен аңлату, тартым-лы исемнәр белән җөмләләр төзеп әй-тергә өйрәтү. | Аралашу барышын-да үзара аңлашуга ирешү; дәрес мате-риалына кызыксыну белдерү. | Дөрес җавапны эзләп таба һәм күрсәтә белү. | [у], [ү ] авазла-рын ишетеп таный,калын һәм нечкә әйте-лешле сүзләрне-аера белү, сорау җөмләләрне куллана алу. | Тема буенча үзләштерелгән сүзләрне кабатлау; сораулар куеп, җөмләләрне әйтү; җөмләләрне дәвам итеп уку; дөрес җавапны табып әйтү;. Хаталар | Сүзләрне кирәкле грамма-тик фор-мада язу. | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | өстендә эш. | | |
| 11 | Тартык авазлар. Ясалма сүзләр. Җәйге ял. | 1 | Тартык авазлар турындагы белемнәрне гомумиләштереп кабатлау; ясалма, кушма,парлы сүзләр турында башлангыч мәгълүмат бирү; җәйге ял турында сөйләшү үткәрү. | Туганнарга карата игътибарлы булу, туган ягың белән горурлану. | Укылган текстның эчтәлегенә бәя бирә белү. | Тартык авазларны сөйләмдә дөрес әйтә белү, ясалма сүзләрнең мәгънәләрен аңлау һәм аера белү, тема буенча бәйләнешле текст төзеп сөйли алу. | Яңа сүзләрне тыңлау һәм кабатлау; диалогны тулыландыру; текстны уку һәм эчтәлеген сөйләү; ясалма, парлы һәм кушма сүзләрне куеп. җөмләләрне уку; тизәйткеч өйрәнү. | Тест № 1 | |
| **Кеше һәм сәламәтлек – 11 сәг.** | | | | | | | | | |
| 12 | *г* хәрефе. Көндәлек режим. | 1 | Татар телендә *г* хәрефенең ике аваз белдерүен аңлату; тема буенча укучыларның бәйләнешле сөйләмен үстерү. | Көндәлек режимны саклауның сәламәтлек өчен файдалы булуын аңлау. | Проектлар төзи белү. | *г* хәрефле калын һәм нечкә әйтелешле сүзләрне аера белү; сөйләмне лексик яктан дөрес оештыра алу. | Яңа сүзләрне күмәк рәвештә әйтү; сүзтезмәләрне тулыландыру; җөмләләрне дәвам итеп уку; текстны уку һәм эчтәлеген сөйләү; җөмләләрне тәрҗемә итү. | Тест №22 | |
| 13 | ***В*** хәрефе Саннар. Сәламәт көнкүреш. | 1 | *В* хәрефенең ике аваз белдерүен аңлату, рус телендәге шул ук хәреф белдергән авазны чагыштырып күрсәтү, сорау-җавап репликаларын кулланырга күнектерү. | Спортның әһәмиятен аңлый, үз сәламәтлегеңне үзең кайгырта белү. | Сәламәтлек турында аралашып, логик фикер йөртә алу. | *В* хәрефле сүзләрне дөрес әйтә белү; укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирә алу, өйрәнелгән грамматик формаларны дөрес куллана алу. | Текстны уку һәм сорауларга җавап бирү; яңа сүзләрне истә калдыру; саннарны кирәкле килешләрдә куеп, җөмләләрне язу; җөмләләрне дәвам итеп уку; тартымлы исемнәрне кабатлау. | Сорау алмашлыклары белән җөмләләр төзеп язу. | |
| 14 | Саннар. Кеше ничек үсә? | 1 | Актив лексиканы гамәли үзләштерү; | Үзеңнең үсешеңә тиешле игътибар | Кешенең үсеше сәламәтлеккә | Актив үзләштерелгән сүзләрне | Яңа сүзләрне истә калдыру; охшаш | Фронталь әңгәмә; | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | саннарны дөрес кулланырга күнектерү, укучыларның диалогик сөйләмен үстерү; кеше үсеше турында сөйләшергә өйрәтү. | бирә белү. | бәйле булуын белү. | сөйләмдә дөрес әйтә белү; тема буенча бәйләнешле сөйләмне дөрес оештыра алу. | диалог төзү; текстны укып, сорауларга җавап бирү; дөрес җавапны табып язу; сораулар куеп, җөмләләрне уку. | мәкальләрне яттан әйтү. | |
